
# МИН — СЕБЕР ТАТАРЫМЫН!

# МИН — СЕБЕР ТАТАРЫМЫН!



*Шигырьләр*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Там)-5
М50

Төзүчесе һәм кереш сүз авторы
*Рафис Корбан*

М50 Мин — Себер татарымын!: Шигырьләр / Төз. һәм кереш сүз авт. Р.Х.Корбан. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 160 б.

ISBN 5-298-03908-1

Җыентыкка Төмән өлкәсендә яшәүче һәм шул төбәктә туган Себер татар шагыйрьләренең шигырьләре тупланды.

ISBN 5-298-03908-1 © Татарстан китап нәшрияты, 2006

## БЕЗ ИСӘН!

Татар әдәбияты беркайчан да узурпатор коммунистлар кысалап куйган Татарстан дигән республика территориясендә яшәгән татар халкы әдәбияты гына булмады. Моңа мисаллар китереп торуның хаҗәте юк. Аның географик чикләре киң. Кызганычка каршы, татар телендә укыту, тәрбия бирү мөмкинлекләренең нык кысылуы нәтиҗәсендә аның куллану даирәсе генә тараеп калмады, шулай ук күп төбәкләрдә татарлар урыслашу процессы кичерде, халкыбыз урыс белән ассимиляцияләнеп, әдәбият-сәнгать өлкәсендә дә күп кенә талантлы яшьләребез урыс әдәбият-сәнгатенә хезмәт итүче иҗат кешеләре булып тәрбияләнеп үсәргә мәҗбүр ителделәр. Кыскасы, әдәбиятыбызга чит төбәкләрдән талантлы әдипләр килү бөтенләй диярлек тукталды. Рәсәйдә милли сәясәт алып барылмау (бәлки, бу киресенчә, башка халыкларны урыслаштыру буенча яшерен сәясәттер) нәтиҗәсендә татар дигән милләтнең әле дә шушы көнгә хәтле яшәп килүенә бер караганда гаҗәпләнергә, сокланырга һәм горурланырга кирәктер!

Әйе, без исән, без бар! Әле тегендә, әле монда үзебезнең үлемсезлегебезне, яшәүчәнлегебезне күрсәтеп, тавышыбызны ишеттереп торабыз.

Сезнең кулыгызга килеп эләккән әлеге җыентык та, хөрмәтле укучылар, менә шуның матур бер мисалы. Бу китап әдәбият сөючеләрне Төмән өлкәсендә яшәгән һәм бүгенге көндә яшәүче Себер татар шагыйрьләренең иҗатыннан үрнәкләр белән таныштыру юнәлешендә әле беренче адым. Әлбәттә, җыентыкта урын алган Булат Сөләйманов, Шәүкәт Гаделша кебек шагыйрьләр иҗаты

Татарстан укучысына яхшы мәгълүм. Калганнарының да төрле нәшриятларда шигырь җыентыклары басылып чыккан.

Бүген Төмәндә 1990 елдан бирле чыгып килүче «Яңарыш» газете редакциясе каршында «Әдәби Төмән» берләшмәсе эшләп килә. Аны оештыручылар — газетнең беренче баш мөхәррире Азат Сәгыйтов (кызганычка каршы, бүген инде ул вафат, аның башлаган эшен хатыны Алсу ханым дәвам иттерә) һәм Төмән дәүләт университеты профессоры Хәнисә Алишина була.

«Яңарыш» үзенең беренче саннарыннан ук Төмән өлкәсе татарларының милли-мәдәни тормышын яктыртуга зур игътибар бирә. Әлбәттә инде төбәкнең әдәбият-сәнгать әһелләре иҗатына зур урын бирелә. Шулай итеп газит гомерләре буе әдәби иҗат белән шөгыльләнеп тә, әсәрләрен дөньяга чыгару мөмкинлегеннән мәхрүм булган авторлар өчен иҗат мәйданына, иҗат лабораториясенә әверелә. Алар газиттә әсәрләрен бастырып кына калмыйлар, редакциягә җыйналып, әдәби берләшмә утырышларында үзара фикер алышалар, киңәш-табыш итәләр, эшлекле сөйләшүләр, иҗади бәхәсләр алып баралар. Сирәк кенә булса да Казаннан язучылар, шагыйрьләр чакырып, үз иҗатлары хакында аларның фикерләрен уртаклашкан очрашулар үткәрәләр.

2004 елда «Әдәби Төмән» берләшмәсенең чираттагы семинарларының берсендә шагыйрьләр Шәүкәт Гаделша һәм Газинур Морат белән бергә минем үземә дә катнашырга насыйп булды. Казан шагыйрьләре килә дигәч, «Яңарыш» редакциясенә Төмән өлкәсенең үзәктән шактый ук еракта урнашкан төбәкләреннән дә каләм тибрәтүче һәвәскәрләр килгән иде.

Төмән татар әдәбиятына, сәнгатькә шактый гына үзенчәлекле әдипләр, галимнәр, сәнгать әһелләре биргән төбәк. Күренекле фольклорчы, татар фольклористикасына нигез салучыларның берсе, әдәби җәмәгатьчелегебез 2004 елда 100 еллыгын билгеләп үткән галим Хәмит

Ярми Төмән өлкәсенең Кырын Күл авылында туып үскән. Кырын Күлдә бүген Төмән өлкәсендәге бердәнбер татар мәктәбе сакланып калган һәм эшләп килә. Шушы мәктәп укытучысы, шулай ук күренекле фольклорчыбыз Флора ханым Әхмәтова-Урманченың сеңлесе — Фәридә Наримановна Ермышева (Ярми-Ярмөхәммәтовлардан үзгәртелгән булуы мөмкин) күренекле авылдашының музеен оештырып, аның турында бай мәгълүмат туплап, якташлары истәлеген кадерләп саклый.

Төмән районындагы Ямбай авылында 1884 елда салынган, ул заманда зурлыгы белән Россиядә Петербургныкыннан кала икенче урында торган мәчет сакланып калган. Бүген ул мәчет территориясендә мәдрәсә эшләп килә, район архитектура-тарих музей-тыюлыгы урнашкан. Заманында ул мәдрәсәдә татар, казах телләрендә әсәрләрен язган күренекле Себер татар мәгърифәтчесе, шагыйрь Мәүлекәй Юмачиков эшләгән. Х.Ярминең әтисе Хөснетдин мулла менә шул шагыйрь-мөгаллимнең әлеге мәдрәсәне тәмамлап чыккан беренче шәкертләреннән булган.

Әлбәттә, әсәрләренең Татарстан китап нәшриятында басылып чыгуын күрү Төмән әдипләренең якты хыялы. Төмән шагыйре, урыс нәшриятларында Мәскәүдә, Екатеринбургта, Төмәннең үзендә калын-калын томнар чыгарган, хәтта шигырьләре инглиз теленә тәрҗемә итеп басылган Николай Шәмсетдиновның да Казанда китабы чыкканын күрү — зур хыялы. Николай Меркамал улы Шәмсетдинов — безнең Рөстәм Кутуй, Диас Вәлиев, Лилия Газизовалар хәлендәге кеше — урыс телле шагыйрь. Ләкин әсәрләрен татар телендә дә күрсәтәсе килә, туган халкына укытасы килә.

Күренекле әдип, Г.Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты Якуп ага Зәнкиев бүген инде вафат, ләкин ул «Яңарыш»ның актив хәбәрчесе булган, аның тирәсендә сәләтле иҗат әһелләрен туплау буенча күп кайгырткан. Төмәнлеләр бу күренекле якташлары белән бик

горурланалар, аның якты истәлеген көнелләрендә тирән саклыйлар.

Бүген Төмәндә шулай ук Сәгыйт Сәгыйтов, Заһид Акбүләков, Галия Абайдуллина, Клара Кучковская кебек шактый гына сәләтле, каләмле шагыйрьләр иҗат итеп ята. Аларның инде төрле нәшриятларда берничәшәр китаплары басылып чыккан. Семинарда тыңлаганнан соң без хәтта бу шагыйрьләрне Татарстан Язучылар берлегенә әгъзалыкка тәкъдим итәргә кирәк дигән нәтиҗәгә килеп кайттык.

Төмәндә шигырь җене кагылган, язмыйча яши алмый торган, язмаларын дөньяга, халыкка чыгару, милләтенә күрсәтү уе белән яшәүче кешеләр бик күп. Киләчәктә «Әдәби Төмән» берләшмәсе матур гына эшләп китсә, бу язучылар, шагыйрьләр барысы да үз ниятләренең тормышка ашуына ирешерләр, Ходай бирсә.

Сөендергәне тагын шул булды — алар арасында үз хезмәтләрен дөньяга таныту эшен кайгыртучылар бар. Атказанган укытучы, Россия Федерациясе халык мәгарифе отличнигы исеменә лаек булган, гомере буе Төмән өлкәсе Вагай районы Акъяр мәктәбендә тел-әдәбият дәресләре укыткан Люция Хәбибуллина — Төмән мәктәпләре өчен «Туган як әдәбияты» дигән ике томлык хрестоматия төзеп, Себер татар язучыларын дөньяга танытуда бәяләп бетергесез зур хезмәт башкарган милләтпәрвәр.

Безне шатландырган тагын бер күренешне атап үтмичә мөмкин түгел. Иң мөһиме — Төмәндә үз язучыларын таныйлар, хөрмәт итәләр, алар белән сөйләшәләр. «Әдәби Төмән» берләшмәсе семинарында катнашу өчен хәтта Төмән өлкәсе татарларының милли-мәдәни мөхтәрияте башкарма шурасы рәисе Әхтәм Хәмит улы Каюмов та килгән иде. Семинар утырышыннан соң һәм икенче көнне безне — семинарда катнашучыларны — төрле очрашуларга, Төмән районының истәлекле урыннарына алып бардылар. Очрашуларның берсенә, Кырын Күл мәк-

тәбендә үткәненә Төмән өлкәсе Дәүләт Думасы рәисе урынбасары Геннадий Корепанов, Дума депутаты Ришат Сабирович Җиһаншиннар килгән иде. Алар берләшмә әгъзаларының, татар теле укытучыларының, Төмән өлкәсендә яшәүче татарларның бүгенге хәле, татар телен һәм әдәбиятын укытуның торышы, үз алларында торган проблемалар хакында борчылып сөйләүләрен зур игътибар белән тыңладылар, аларны хәл итү буенча, һичшиксез, чаралар күреләчәге хакында ышандырдылар.

Безне шулай ук Төмән өлкәсендәге иң алдынгы авыл хуҗалыгы предприятиесе булган «Лукоэл-Каскара» комплексына алып бардылар. Төмәндә колхоз-совхозлар Россиянең Татарстаннан кала башка регионнарындагы шикелле үк, нигездә, таркалып, бөлеп беткәннәр. Ә менә килгәнбер кунакка күрсәтерлек үрнәк хуҗалык булып калган алдынгы Каскара хуҗалыгында татар авыллары икән! Хуҗалыкка өч авыл берләшә — Зур һәм Кече Каскара, Талымхан. «Без татар авыллары булганга, татарлар аркасында гына яшәп кала алдык», — диде хуҗалык җитәкчесе Иван Федорович Каргаполов. Безне Талымхан авылына алып бардылар, биредәге балалар бакчасын, заман таләпләренә җавап бирә торган итеп җиһазландырылган урта мәктәпләрен күрсәттеләр. Бу мәктәпне күреп, без, төрле мәктәпләрдә очрашуларда еш булган татар шагыйрьләре аһ иттек! Ихлас әгәр, күпме мәктәпләрдә булып, мондый мәктәпне әле минем беркайда да күргәнем юк иде!

Талымханнан соң Төмәнгә кайтып, «Этнос» исемле төрки балалар иҗат үзәгенә бардык. Заманында Тәнзилә Ильясова исемле милләтпәрвәр ханым тырышлыгы белән оештырылган, бүген Венера Ивановна Хәйруллина кебек фидакарь ханымның тырышлыгы белән яшәп килүче әлеге үзәк хакында да, Төмән шәһәрендәге милли мәдәниятләр сарае каршында эшләп килүче татар мәдәнияте бүлеге фидакарьләре хакында да, Төмән өлкәсендә милли рухыбызны саклап килгән татар теле, әдәбияты укыту-

чылары хакында да, ару-талуын белмичә, заман авырлыклары каршында сыгылмыйча-бөгелмичә өлкәдә иң алдынгы авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре данын яулаган милләттәшләребез хакында да, Төмән журналистлары, шагыйрьләре, әдипләре хакында да җәелеп, тәфсилләп әллә никадәр сөйләргә, язарга мөмкин булыр иде. Ләкин мин язмамны шушы урында түгәрәкләп, үземнең сөекле халкым белән соклану хисләрем хакында гына әйтәсем килә. Кайда гына яшәсәк тә, без — татарлар — эш сөючән, тырыш, булдыклы халык, үз алдыбызга куйган максатка ирешмичә туктала белми торган халык. Төмән шагыйрьләре дә үз алларына олы максат куйганнар әнә — профессиональ яктан тагын да үсәргә, осталыкларын арттырырга, бөтен татар дөньясына үз әсәрләрен танытырга. Һәм аларның бу максатларына ирешәсенә минем күңелдә һич кенә дә шикләнү тойгысы юк. Без исән әле, без яшибез!

*Рафис Корбан*



# МӘУЛЕКӘЙ ЮМАЧИКОВ

*(1838—1910)*

*Мәүлекәй Юмачык улы Юмачиков 1834 елда Тубыл губернасы Ялутор өязе Манчыл авылында туа (авылның хәзерге исеме — Ямбай), гомеренең күп өлешен казах арасында үткәрә. Күләмле әсәрләрен (башлыча кыйсса, дастаннарын) казах телендә иҗат иткән. Татарча язган шигырьләре һәм казахчага тәрҗемәләре дә күренекле урынны алып торалар. Ул 1910 елда вафат була. Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты бүгенге көнгә кадәр җентекләп өйрәнелмәгән. (Аның турында башлангыч мәгълүмат «Татар әдәбияты тарихы»ның 2 нче томында басылды. 398—402 б.)*

## Эрбет бәете*

Бу дөнья мисале Эрбеткә охшар[1],
Ахыры һәм ахирәт юлга охшар.

Падишаһ Екатерина булыптыр[2],
Заманында бу Эрбеткә килептер,

Император фатихасын бирептер;
Төрекдән дә, Кытайдан да килептер.

Безнең патша Белый чар[1] улыптыр,
Александр Николаевич улыдыр[3].

Вафат булса, аңа яхшылык улсын,
Яңа падишаһ дәхи рәхимле булсын.

Дәхи рәхимле булсын ул санатлар[2],
Падишаһ хәзрәтендән ул канатлар.

Санатның берсе — Чизурнай[3] комитет,
Безнең өчен бу бәеткә рәхим ит.

Александрның углы Александр[4],
Яңа падишаһ улыдыр император.

Озын булсын гомере ничә елга,
Балалары, хатын-кызлары янә.

---

[1] *Чар* — царь.
[2] *Санатлар* — сенатлар.
[3] *Чизурнай* — цензурный.
* Калын саннар белән бирелгән искәрмәләрне 31 биттән кара.

Аларны сакласын һәрир бәладин,
Яманлык күрмәсен агай-энедин.

Яд[1] иттем аз гына падишаһ хәлендин,
Азрак язаем үз хәлемдин.

Мәнем атым Мәүлекәйдер, беләрсез,
Үземне күрсәнез, бәлки, танырсыз.

Бу Эрбеткә барып йөрдем әввәлдин,
Таза белдем бу Эрбетнең хәлләрен.

Бу Эрбет хәледин бераз сөйләен,
Бераз гына нәсихәтне[2] кыламын.

Дәхи бәгъзе кешеләр анда бардыр,
Үзенә һәм яман юлдашаладыр.

Шулар безнең кашымызга[3] киләдер,
Минем тозак икәнемне беләдер.

Буңар җәзам — мәне алып китәләр,
Ки һәртөрле фәсад[4] эшне итәләр.

Шулар илә фәсад эшләре кыйлдым,
Көне-төне яманлыкта йөредем.

Ашап-эчеп олубән мәсте[5] сүккән,
Орыш-сугыш вә гафләт[6] берлә һәр ан.

---

[1] *Яд* — искә төшерү, телгә алу.
[2] *Нәсихәт* — үгет, яхшылыкка өндәү.
[3] *Кашымызга* — каршыбызга.
[4] *Фәсад* — бозыклык, азу, әшәке эш.
[5] *Мәсте* — исерек, исергән.
[6] *Гафләт* — саксызлык, гамьсезлек.

Ни өчен белмәдем һич килдегемне,
Танымадым көне-төн булдыгыны.

Сату өчен һич улмады сагышым,
Шуның өчен булмады мәнем табышым.

Качан ярмункәнен[1] ахры йитте —
Халаек барчасы йортына кайтты.

Хисап итте үзенең һәм малына,
Тугәргә булмады фатир ялына.

Хисап итен караса, калды хәйран,
Үзенең кылдыгый малына вәйран[2].

Кирәк эшне һичбер кылмадым мән,
Кирәк заттан дәхи һичнәрсә алмадым мән.

Үзенең калдыгына кала хәйран,
Бу рухидан котылалмый улды пошиман.

Дәхи һич курмәдем йортның чырагын[3],
Белә алмадым кайтуга юл ерагын.

Түгәм хәсрәт белән күздин яшьне,
Агызып яшьли илә ике күзене.

Диям: хәсрәт белән бән кичсәмче,
Чү кәлдем мән бу эшне кыйлсамчы.

Чү кәлдем бән, трактир кермәсәмче,
Бу харчәүнәм — саташып йөрмәсәмче.

---

[1] *Ярмункә* — ярмарка.
[2] *Вәйран* — ватык, жимерек, хәрабә хәленә.
[3] *Чырагын* — лампа, ут, яктылык.

Бу харчәүнәм — эчемлек эчмәсәмче,
Бер трактирым — серемне чишмәсәмче.

Бу хәл илән ничек кайтып китәен,
Бурычымны ничек итеп үтәен?

Тәмам хәсрәт илә кайтып киләдер,
Җәмәгате аны күреп көядер.

Җәмәгатьләренә һичбер бүләк юк,
Угыл-кызларына һәм кучтәнәч юк.

Җатыр йортында бурычка буялып,
Өеннән чыкмаен ятыр оялып.

Шикаять[1] кылдым үземнең эшемдин —
Монның кебек булып йөргән кешедин.

Рәхмәт яусын, Ходаем, шул кешегә —
Сатып сәүдә кыйлып йөргән эшенә.

Алырлар анда һәр мәнзел[2] каюсы,
Үзенең хәленә лаек камусы[3].

Тырышып бәгъзесе сәүдә кыйладыр,
Мөкаддәр[4] ризыкыны һәр көн аладыр.

Һәм исраф итмәс анда үзе бер пул[5].
Җыеладыр бәс анда күп пол.

---

[1] *Шикаять* — зарлану, сукрану.
[2] *Мәнзел* — йорт, торак, тукталп китә торган урын.
[3] *Камусы* — сүзне.
[4] *Мөкаддәр* — билгеләнгән, тәкъдир ителгән.
[5] *Пул (пол)* — акча.

Фикер итеп йөрер ул үз хәлен,
Урынсыз йиргә сарыф итмәс малын.

Афәрин ул кешеләрнең хәлenә,
Ходай өчен сарыф кыйлган малына!

Буларның эшедин гыйбрәт алаек,
Насыйп булса яманлыкны куяйык.

Ходаем, рәхмәт иткел син, фәкыйрьгә,
Янә тәүфыйк насыйп ит без фәкыйрьгә.

Бәс имде анласаң ярмункә хәлен,
Дәхи сән аңлагыл бу дөнья хәлен.

Адәм угланнары монда кәлепмәз,
Тәмам дөнья арасына тупмаз.

Тотынып һәрберенә бер ватанны,
Үземезгә лаек кылып мәкянны[1].

Вәләкин ул ватан мәңгелек ирмәс,
Аның вәгъдәсене һич кемсә белмәс.

Кайчан вәгъдә ирешсә, чыкар андин,
Куеп ул ватанны китәр андин.

Асыл ватан түмгәрер[2] бәс[3] бу дөнья
Гөман итче бәнемдер дип бу дөнья.

Сәнең кеби ничәләр үтте-китте,
Ничә шаһлар, нәбиләр[4] үтте-китте.

---

[1] *Мәкянны* — торган жир, торган урын.
[2] *Түмгәрер* — бетәр, югалыр.
[3] *Бәс* — димәк.
[4] *Нәбиләр* — пәйгамбәрләр.

Бу үлемдән котылмыш кемсә юктыр,
Бәс аны тотмаен һич чара юктыр.

Сән үзең, Мәүлекәй, бик күп куанма,
Сәнең дин бер гөнаһкяр бәндә торырмы.

Сәңа да ошбу вәгъдә бер киләчәк,
Кайда китте атаң сәнең Юмачык?

Үзең һәм бергә сән ошбу вәгазьдә,
Үзең үлсәң, хатың калыр кәгазьдә.

Гакылсыз, язмагыл күп сән атыңны,
Күләрләр укыган адәм хатыңны.

Фәкыйрь үлсын, гани үлсын бу инсан,
Үлдем татымак хакында җөмлә иксан[1].

Үлем чоңгылыга ахыр төшәрсең,
Бу дөньяны куеп ахыр китәрсең —

Бу дөньяның әгәр сән шаһы булсаң,
Тәмам йир йөзенең солтаны булсаң.

Бәс имде фикер кылгыл үз халкыңны,
Бу дөньяга ни өчен килгәнеңне.

Гыйбадәт кылмага килдең Ходага.
Итагать[2] кылмага килдең Ходага.

Ни боерса, Ходаем, аны кылгыл,
Нидән тыйса сәне — андин тыелгыл.

---

[1] *Иксан* — яхшылык.
[2] *Итагать* — буйсыну.

Юмартлык кыл, саранлык кыйлмагыл һич,
Тәвазигь[1] кыл, тәккәбер улмагыл һич.

Золымлык кылмагл һәргиз[2] кешегә
Гадәләт[3] әйләгел һәрбер кешегә.

Төне-көн иҗтиһад кыл яхшылыкка,
Яманлык кыйлмагыл һичбер халыкка.

Рәхим ит сән фәкыйрь — мискин гидайга[4],
Тәзарруг[5] әйләгел даим Ходага.

Үлемне даимән янында белгел,
Анын илкен гарибанда[6] белгел

Өмет итик бу дөньяда яканны,
Тотар бер көн үлем ахыр яканны.

Үзеннен гафләтендин[7] сән уянгыл,
Халыкның хәленнән гыйбрәтне алгыл.

Халыкның изгесен күреп ияргел,
Яманларны күреп гыйбрәтне алгыл.

Үлем кәлмәз борын, кыл изгелекне,
Үзен рәхәт улур чүн мәнгелекне.

Асыл йорт булмаса имди бу дөнья,
Асыл йорт нә идекен имде анла.

---

[1] *Тәвазигь* — түбәнчелек итү.
[2] *һәргиз* — һәрвакыт.
[3] *Гадәләт* — гаделлек.
[4] *Гидай* — ярлы.
[5] *Тәзарруг* — ялвару.
[6] *Гарибанда* — якада.
[7] *Гафләтендин* — ваемсызлыгыннан.

Бу дөньяда һәрмез дә кунакмыз,
Ничә көнләр торыр өчен кәлепмез.

Фикер кыл имди уена кайтмакыңны,
Ни хәзерләп, ни алып китмәгеңне.

Әгәр бер кемсәнә дөньяга килсә,
Ни өчен килдеген анда белсә,

Ходаем ни боерды — аны кылса,
Дәхи тыйганларындин ул тыелса,

Ходага кылса һәрдаим итагать,
Гомерне кылмаса һәргиз изагать[1],

Зарарны кыйлмаса һәргиз халыкка,
Мәйле кылмаса ул яман холыкка,

Гадәләт белән булса һәр эшендә,
Золымлык кыйлмаса һичбер эшендә,

Әҗәл килсә, төкәлсә гомре аның,
Каралып үлсә үлемгә хәле аның,

Бәшарәткә[2] фәрештәләр килерләр,

Бәшарәтне аңа ул дәм[3] бирерләр.

Сәңа юктыр бу көндин соң яманлык,
Сәнең эшең һәмишәдер һаманлык.

Котылдың имде дөнья михнәтендин,
Өмет иткел Ходаның рәхмәтендин.

---

[1] *Изагать* — әрәм итмәү, бушка үткәрмәү.
[2] *Бәшарәт* — шатлык, сөенеч.
[3] *Дәм* — мизгел.

Ə мин соң инде дузәх[1] михнәтедин
Өмет иткел Ходаның нигъмәтедин.

Аны күреп тәмам сәвенгәй[2] анда,
Бу дөньяны тәмам оныткай анда.

Бу шатлык илә вирә ул җаны,
Оныткай ул угыл-кызы, малыны.

Əгәр бер кемсә дөньяга килсә,
Ни өчен килдегендин гафил[3] улса,

Хода әмренә барча кылмаса ул,
Дәхи тыйганнарындин тыелмаса ул.

Дәхи ул изгелекне кылмаса һич,
Яманлык әйләсә ул иртә вә кич,

Золымлыкны һәмишә әйләсә ул,
Гадәләт нә идекен белмәсә ул,

Качан гомре фәна улса[4] төгәнеп,
Газап фәрештәләре аңа кәлсә —

Белер ул вакыт әҗәлнең тидегене,
Гомер үтеп, төгәнеп беттегене,

Фикер итәр үзенең үлмәгене,
Караңгы тар ләхедкә кермәгене.

Кабердә һәм газапта ятмакыны,
Терелеп кабердә һәм тормакыны,

---

[1] *Дузәх* — тәмуг.
[2] *Сәвенгәй* — сөенгәй.
[3] *Гафил* — белмәүче, искәрмәүче.
[4] *Фәна улса* — бетсә.

Асыл йорт анда ике улмакыны,
Йә җәннәт, йә җәһәннәм улмакыны,

Алып барыр гамәлнең юклыкыны,
Кире кайтырга дәрман юклыкыны.

Дия: бәс дөньяга бән килмәсәмче,
Чү, көлдем бары инсан үлсәмче.

Чү инсан үлдем балигъ улмасамчы,
Чү үлдем мән форсатны кыйлмасамчы.

Буның тик үкенгәй ул заманда,
Вәләкин ул үкенсәң дә нә файда!

Бу дөньядан үтеп китмәк хәле —
Сәфәрдән йортына кайтмак мисале.

Бәс аңладыңмы инде әйттегемне,
Бу дөнья мисале Эрбет дидегемне?

Бу Эрбет дәхи ике төштә монда,
Ни мошакгать[1] күреп идем мән анда.

Бу Эрбетнең ике йөзе бар икән:
Берсе ак, берсе кара икән.

Сәңа ул ак йөзе белән караса,
Сәңа дәүләт улырнидай караса,

Караса сәңа ул кара йөз илә
Ияреп китәсен хәннас[2] сүз илә, —

[1] *Мошакгать (мәшәкъгать)* — мәшәкать.
[2] *Хәннас* — явызлык, аздыручы, шайтан.

Бу Эрбетнең бете һәм бик эредер,
Гакылсызның кабыргасын чийидер[1].

Бу Эрбет бер олы беткә ошайдыр,
Күп ойокласаң[2] кабырганны ашайдыр.

Бу Эрбет күктә яткан бөркеттер,
Гафилләр көтә өстенә китәдер.

Бу Эрбет язгы аккан боздай икән,
Таеп китсәң, таяныр йир жук икән.

Берәүгә күрсәтер Эрбет битене,
Берәүгә дәхи күрсәтер күтене.

Бу Эрбетнең ике башы бар икән:
Берсе аждаһа дик бик зур икән.

Аямаяк гафилләрне жотадыр,
Качар булсаң йибәрмәй һәм тотадыр.

Башының берсе дәүләт кошы икән,
Агзын ачубән[3] гәүһәр сачә икән.

Шуның кебек йите башлы бу дөнья,
Адәм углы берәвендә тотыла.

Йите башы дигәнең — йите көндер,
Йите көннең берендә китүеңдер.

Бу дөньяның унике кул буладыр,
Бәни адәм бересендә буладыр.

---

[1] *Чийидер* — тешли, чиләндерә.
[2] *Ойокласаң* — йокласаң.
[3] *Ачубән* — ачу белән.

Утыз бармак башында һәр кулының,
Хисабы юк ахирәтнең юлының.

Әҗәл тимәй бераз көн котылырмын,
Үз бармакның берендә тотылырмын.

Унике ай дигәнем — унике кул,
И борадәр[1], газизем, сән моны бел!

Ни өчендер мәнем күп гамь йийганым[2],
Утыз көндер утыз бармак дигәнем.

Бу көнең бел, бәндә, укуыңны,
Бу дөньяны кую бән китүеңне.

Бу дөньяда ни гамәлне кылырсың,
Кыямәттә җәзасыны күрерсең.

Үзең дә, Мәүлекәй, тот колагыңны,
Карап тыңла колактан булаганны.

Әгәр изгелек итсәң дөньяда сән —
Кыямәттә һәм изгелек күрәсең.

Әгәр бу дөньяда кылсаң яманлык,
Бәс, ул көндә табарсың һәм яманлык.

Кеше богдай сачеп арпа алалмас,
Яман эшдин дәхи файда табалмас.

Золымлык кылма, андин саклана күр,
Үзеңне сән андин ерак итә күр.

---

[1] *Борадәр* — ир туганым.
[2] *Гамь йийганым* — кайгы күрү.

Бу дөньяда әгәр сән хаким улсаң,
Гадәләтне кыла күр, кадир[1] улсаң.

Үлемнең вакты килсә — үкенерсең,
Үзеңнең һәм ни кылганың күрерсең.

Бәс ул вакыт үленмәк лаек улмас,
Һәм анда үкенүдән файда улмас.

Бәс, инде тәүбәне хәзер кылаек,
Һәм Аллага гыйбадәтне кылаек.

Безнең гыйсъянымызны[2] күрәдер ул,
Һәм әхвалебезне беләдер ул.

Дөнья имәс безнең гыйсъянымызга,
Ризасыдыр аның ихсанымызга[3].

Ходаның боерганын бар кылмадык һич,
Дәхи тогыянларын[4] куймадык һич.

Гөнаһмыз күп улды, тулды дөнья,
Шуның чөн фетнә илә тулды дөнья.

Гөнаһ өчен бирә безгә җәзаны,
Гамәлләремезә лаек җәзаны.

Аны үз фигыльләремездән дип күрәмез,
Үзмезнең гөнаһымдин дип беләлек.

Аның чүн һич кешегә үпкәмез юк,
Сабырдин гайре дәрманмыз юк.

---

[1] *Кадир* — бөтен нәрсәгә көче житүче.
[2] *Гыйсъян* — тыңгысызлык.
[3] *Ихсан* — яхшылык, изгелек итү, ярдәм.
[4] *Тогыянларын* — билгеләнгән эшләрен.

Шуның чөн фетнәләргә мөбтәләбез[1],
Шуның чөн һәр бәлагә мөбтәләбез.

Бу дөньяда будыр инде хәлемез,
Кыяммәттә ничек улыр хәлемез?

Бу дөньяда ушы хәлне белеп ал,
Бераз гына сүзенгә колак сал.

Сүземне кыскалык берлән сөйләрмен,
Аны мөмкин кадәр җималь идәрсең.

Сүзем тәнавел[2] итәргә йитмәде хәл,
Аны тәфсил итәргә булды мәҗаль[3].

Падишаһ бездин аладыр имана,
Бу сүземне гаепкә ала күрмә.

Ничә патша бу дөньяның йөзендән,
Хираҗ[4] алыр барысы җир йөзендән.

Тиешледер гадәттә хираҗ алмак,
Тиешледер безә һәм разый улмак.

Әгәр белсәң аның хөкеме гаделдер,
Ничә төрле халыкка бәрабәрдер.

Кадим заманда булган падишаһлар,
Ишетсәң — һәммәсенең гаскәре бар.

Дисәң: солдат аладыр баладан,
Падишаһлар алып килгән әвваләдән.

---

[1] *Мөбтәләбез* — дучар булабыз.
[2] *Тәнавел* — эчеп, кабып карау, авыз итү.
[3] *Мәҗаль* — көч.
[4] *Хираҗ* — түләү.

Бу безнең үзмезне саклар өчен,
Янә куйды хакимләр саклар өчен.

Бу падишаһдин һичбер гадел юк,
Безем һәм динемезгә һич зарар юк.

Урыс та һәм безнең хакны йиярмәй,
Дөнья башка дип һәм башка күрмәй.

Күрәдер ул үз баласыдай барын:
Урысның һәм мөселманның барын.

Дин өчен мөфти йә хәзрәт куептыр,
Янә указнай имамлар куептыр.

Тынычлыкта яту мисле даладыр дик,
Гүяки без бишектәге бала дик.

Хаким куйды урыстан безнең өчен,
Ямандан, угрыдан саклау өчен.

Бунын кебек ничә төрле хакимләр,
Мөселмандан начальниклар янә бар.

Барысы безнең өчен куелыптыр,
И диган сүзләремне сән белеп тор.

Булар һәм куелыптыр хөкем итәргә,
Яманлыкдин халыкны мәнигъ[1] итәргә.

Халык золым иткәй өчен бер-беренә,
Дәхи золым итмәс өчен үзләренә.

---

[1] *Мәнигъ* — тыю.

Угрылыкдин тыелсын дәю анлар,
Фәсадны[1] кылмас дип һәм яманлар.

Итәргә халык арасын яхшы тәфтиш[2],
Белеп тәхкыйг[3] итәргә аны тәфтиш.

Янә бер мәхкәмәне[4] ясамышлар,
Аны кантур дип тә атамышлар.

Галава дирләр аның рәисене,
Халык үзрә хөкем кылгу хәсиятенә.

Болар бик тугры хөкемне итәрләр,
Приисакларын бик нык тотарлар.

Әгәр тугры хөкем итмәсә алар,
Монда зур чинауниклар киләләр,

Кыек кылган эшен теркәп китәләр,
Ни өчен тугры булмадың, диләр.

Аның бәгъзесе бик тугры буладыр,
Кара кылны тәмам кырка буладыр.

Аларга тугры булмай һич язмаз,
Шуның өчен бүләгенә карамаз.

Баең, ярлыга бердәй булалар,
Сәнең акчаң белән нә кылсын алар.

Чинаукникларга лаек тугры булмак,
Падишаһ хәзрәтенең күнлен алмак.

---

[1] *Фәсад* — бозыклык, әшәке эш.
[2] *Тәфтиш* — тикшерү, төпчену.
[3] *Тәхкыйг (тәхкыйк)* — хак, дөрес.
[4] *Мәхкәмә* — хөкем йөртү, суд бинасы.

Әгәр кылса булар бераз яманлык,
Закунда булыр иде ул угрылык.

Чинауниклар ничек кылсын угрылык,
Закунда күрәдер андар тугрылык.

Олуглар кылсалар иде яманлык,
Главада була алмаз ди тугрылык.

Гакыллысы падишаһдин ояла,
Яманлыкны тиз үк падишаһ белә.

Залим булса глава һәрбер эштә,
Писаре һәм аның белән бер эштә.

Әгәр белсә иде аны олуглар
Гакыллары фирасәтле[1] тулуглар.

Риза булмаслар иде бәс ул эшкә,
Саладыр дип куркадыр ала бер эшкә.

Шуның өчен яманлыкны кыла алмай,
Писер аның сүзендин һәм чыга алмай.

Дип уйлайлар: әгәр белсә министр,
Язып салыр бу эшкә бер реестр.

Рәгыятькә[2] кыл дип мәрхәмәтне
Кылып салыр бу эшкә мәслихәтне.

Гакыллысы угрыны тоялар,
Гакылсызы бушатып йибәрәләр.

---

[1] *Фирасәтле* — зиһенле.

[2] *Рәгыйять* — буйсыну, кул астындагылар, бер дәүләтнең халыклары.

Гакыллысы имана жыя илдән,
Гакылсызы йодрык жыя илдән.

Гакыллысы нәсихәт итә илгә,
Гакылсызы бүләкне сала илгә.

Әгәр белсә иде аны санатлар,
Падишаһ хәзрәтедән кул-канатлар.

Әгәр белсә иде моны үзе шаһ,
Кәмале[1] шәфкатендин дияр аһ.

Гакылсызга дияр иде бер сиясәт[2],
Белер иде бу эшне бик кәбахәт.

Зәгыйфь, мискин улса да ул рәгыять,
Падишаһ хәзрәтинә кыла хезмәт.

Бармыдыр аның әһле гыялы[3],
Әгәр чын илә булмаса кәмале.

Тәмам ихлас илә хезмәт итәләр,
Угылларын вә малларын бирәләр.

Ки хәтта мал түгел һәм үзләрен,
Вә бирәләр жанларын, тәнләрен.

Хосусан кем безә әһле вә ислам,
Аларның шәинедер[4] иттифак[5] вә әхкәм[6].

---

[1] *Кәмале* — житешлек, кимчелексез, бөтен.
[2] *Сиясәт* — жәза.
[3] *Гыял* — гаилә члены.
[4] *Шәинедер* — бер әйбередер.
[5] *Иттифак* — союз, берлек.
[6] *Әхкәм* — хөкем итүче.

Телиләр һәрдаим Хактин һидаять[1],
Тарикы мөстәкыймдә[2] истикамәт[3].

Кәламулла илән[4] гамәл кылалар,
Олуг әмергә итагать кылалар.

Аларда юкдырыр касды[5] җинаять,
Олуг әмергә падишага хыянәт.

Кылу болар тугрылыкка иттифакын,
Шуның чүн кылмаялар һич нифакын[6].

Алар нәфгы[7] зарардин ни күрерләр,
Хода тәкъдире иләдер дип беләләр.

Разыйдыр алар һәрбер казага,
Кылырлар сабырыны һәрбер бәлагә,

Беләләр һәм бу дөньяда нилекне,
Бу дөньяга ни өчен килдекне.

Бу дөнья даре михнәт идекен,
Дәхи мөэмингә зиндан идекен.

Дәхи аның вафасы[8] юклыгыны,
Һәм аның һич бәкасы[9] юклыгыны.

---

[1] *Һидаять* — бүләк.
[2] *Мөстәкыймдә* — ныклык.
[3] *Истикамәт* — ныклык, тотрыклык.
[4] *Кәламулла илән* — Коръән белән.
[5] *Касды* — нияте, теләге.
[6] *Нифак* — үзара таркаулык, талаш.
[7] *Нәфгы* — күтәрелү.
[8] *Вафасы* — тотнаклы, тотрыклы.
[9] *Бәкасы* — мәңгелек булу.

Бу бәет язмага бик михнәт улды,
Рөхсәт булса, бу михнәт китәр иде.

Укымаклык моны балдай сөчүктер[1],
Рөхсәтне алу кылдан нәзектер.

Әввәл яздым тугыз китап басарга,
Рөхсәтен алып басып сатарга.

Биреп иде тәмамына рөхсәт,
Аны сатарга мөмкин юк, бирөхсәт.

Барын да бастырып Шәмсетдин алды[5],
Согубәт мәнкуләте[2] үземә калды.

Бу чинзурның теләве бирсен инде,
Бу китапның барына рөхсәт итте.

Бу китаплар исемнәрен әйтәен,
Бәет кылып берәр юлга язаен.

«Шәехе Бәркый», «Сәед Баттал», «Каракол»[6],
Дүртенчесе — «Мөнәҗәт»тер моны бел.

Будыр бишенчесе «Гокъбә» дигәндер,
Янә берсе «Васыять намә» дигәндер.

Йиденчесе — «Салсал кыйсса» дирләр,
Янә берсе — «Әнмүзәҗ» аңа дирләр.

Унынчысы «Сафуан әл манкулат»тер,
Буларның барысына рөхсәт бирептер.

---

[1] *Сөчүктер* — татлыдыр.
[2] *Согубәт мәнкуләте* — авырлыгы, мәшәкате.

Янә берсе «Әнмүзәҗ» дигәнем,
Шуның өчен ике-өч ел гамь йигәнем.

Бу китапны Краев алды сатып,
«Биәҗергә[1] бастырам», — дип китте алып.

Бу бит ошбуларынча тәмам икән,
Бу дөньяда наданлык яман икән.

Сорагын моны синзур хәзрәтедин,
Өмет итеп рөхсәт бирүендән.

Атымдыр Мәүлекәй ибне Юмачев,
Ялутыр өязедер Тубыллык.

Торагым Манчыл илдәдер, Төмәнлек,
Ул илдә күрмәдем һич тә яманлык.

*1881 ел, 3 июль*

[1] *Биәҗергә* — бушка.

**Искәрмәләр:**

1. Эрбеткә охшар — Эрбет (Ирбит) Свердловск өлкәсендәге Ирбит елгасы Ница елгасына кушылган җирдә урнашкан шәһәр. 1631 елда бистә буларак барлыкка килә, 1643 елдан Эрбет ярминкәсе итеп таныла, 1775 елда шәһәр статусын ала.

2. Падишаһ Екатерина булыптыр — Екатерина II (1729—1796). 1762 елның 28 июненнән Россия патшасы.

3. Александр Николаевич улыдыр — Александр III (1845—1894). 1881 елның 1 мартыннан Россия патшасы, Александр IIнең икенче улы.

4. Александрның углы Александр — Александр III (1845—1894).

5. Барын да бастырып Шәмсетдин алды — Шәмсетдин Хөсәенов, Курса авылы крестьяны, китап сату белән шөгыльләнгән. Үз типографиясе булмаган, заказларны Казан университеты һәм Домбровский типографияләрендә бастырып сату иткән.

6. «Шәехе Бәркый», «Сәед Баттал»(1879, 1888, 1889 елларда), «Каракол», «Мөнәҗәт» (1888), «Гокъбә» (1880), «Васыять намә» (1880, 1897), «Салсал кыйсса» (1879, 1888) — М.Юмачиковның Казанда басылган китаплары.

## «Эрбет бәете» турында

Татар әдәбиятында дөньяви мотивлар XIX йөзнең урталарыннан аеруча көчәеп китә. Ләкин үз чорының әһәмиятле мәсьәләләрен күтәргән реалистик әсәрләр элегрәк тә булган икән. Аларның кайберләре — билгесез язучыларның фольклорлашкан әсәрләре. Гасырлар дәвамында халык яратып укыган бу әсәрләр әлегә хәтле тиешенчә өйрәнелеп бетмәгән. Аннан соң, царизмның татар матбугатына каршы алып барган политикасы, цензура тыюлары аркасында аларның күбесе китап булып басыла да алмаган. Әйтик, шундый тыелган әсәрләрдән авторы билгесез «Мәкәрҗә бәете»н искә төшерик. Татар китаплары цензоры барон Виктор Розен отставкага чыккач (1879), аның урынына христиан динендәге гарәп Фадуллаһ Сарруф цензор итеп билгеләнә. Ул «Мәкәрҗә бәете»н басарга рөхсәт бирә. Китап шул ук елның июнь аенда Казан университеты типографиясендә басылып, сатуга да чыга. Бәетнең беренче өлешендә Мәкәрҗә ярминкәсендәге төрле хәлләр аша автор үз заманы кешеләренә үгет-нәсихәт бирә. Ул кешеләрдә яхшы сыйфатлар тәрбияләргә омтыла. Кешеләрне берберләренә яманлык кылмаска, тырыш булырга, фәкать яхшыдан гына үрнәк алырга өнди:

Золымлык кыйлмагыл һәргиз кешегә,
Гадәләт әйләгел һәрбер кешегә,

Халыкның изгесен күреп уяргел,
Яланнарны күреп гыйбрәт алгыл.

Әсәрнең төп өлешендә халыкның хокуксыз хәле, патша чиновникларының башбаштаклыгы, черек бюрократик система, ришвәтчелек һәм социаль изүгә каршы протест күрсәтелә.

Билгеле, бу вакыйга тыныч кына узып китә алмый. Гадәттәгечә, «үтә уяулык» күрсәтүче, татар мәктәбендә рус теле укытучы татар мөгаллимнәре донос язып, губернаторга житкерәләр. Мондый әсәрне бастырырга рөхсәт бирүе өчен цензор Ф.Сарруфны «политик жит-

лекмәгән» дип эшеннән алалар. Аның урынына В.Д.Смирнов билгеләнә. «Мәкәрҗә бәете»нең конфискацияләнгән нөсхәләре яндырыла, наборы таратыла. Аны тарих өчен Казан университеты типографиясе мөдире Готвальд саклап калган. Конфискация вакытында ул берничә китапны үзендә яшереп калдыра һәм шәхси китапханәсен университетка бүләк иткәндә, башка китаплар белән бергә бу нөсхәләр дә гыйльми китапханә фондына эләгәләр.

Себер татары, шагыйрь Мәүлекәй Юмачиков та 1881 елда, «Мәкәрҗә бәете» калыбында һәм аның кайбер юлларын үзгәрешсез алып, «Эрбет бәете» дигән шигъри әсәр язган. Тик ул да цензор В.Смирнов тарафыннан тыелуга дучар була һәм хәзерге көнгәчә басылмаган килеш кала бирә. Кем соң ул Мәүлекәй Юмачиков? Автор үзе турында мәгълүматны бәетнең ахырында биргән:

Атымдыр Мәүлекәй ибне Юмачев,
Ялутыр өязедер Тубыллык.

Торагым Манчыл илдәдер, Төмәнлек,
Ул илдә күрмәдем һич тә яманлык.

Мәүлекәй бу дөньяны Эрбет ярминкәсенә охшата. Тормыш фәлсәфәсен, дөрес яшәүгә нәсихәтне шушы ярминкә тышчасына төреп бирә. Сәүдә итмичә, юкка акча туздырып йөргәннәрне ни көткәнен күрсәтү өчен, бәеткә лирик герой кертеп, үз исеменнән сөйләтә. Аларны «Мәкәрҗә бәете»ндәге кебек җан алу, кабер газаплары белән куркыта:

Бу дөньяда ни гамәлне кылырсын,
Кыямәттә җәзасын һәм күрерсен.

Кеше богдай чәчеп арпа алалмас,
Яман эшдин дәхи файда табалмас...

Бу бәеттә ул, «Мәкәрҗә»дән аермалы буларак, төрле түрәләрне, чиновникларны мактый, алар халыкка тугры хезмәт итәләр, ди. Аларга тугры булмый һич ярамас, чөнки патша гаепләне шунда ук җәзалый, ди. Менә шушылай «Эрбет»нең «Мәкәрҗә»гә капма-каршы эчтәлекле булуы

М.Юмачиковны консерватив карашлы шагыйрь итеп күрсәтә кебек. Бәлки, бу бәетнең тизрәк рөхсәт алып басылып чыгуы өчен шулай эшләнгәндер, социаль заказ буенча язылган булуы да мөмкин. Чөнки аның Манчыл авылы сәүдәгәрләре — бертуган Нигъмәтулла хажи һәм Рәхмәтулла Сәйдуковларны мактап шигырь язуы да билгеле (бу бертуган сәүдәгәрләр Урта Азиягә сәүдә эше белән йөргәннәр). Һәрхәлдә, югарыда әйткәнебезчә, бәет шушы көнгәчә беркайда да басылмаган. Укучыларга тәкъдим ителә торган бу бәет кулъязмасы язучы Әхмәт Фәйзинең шәхси архивыннан табылды. Ул совет чорында күчереп алынган. Кулъязма хәзерге вакытта Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кулъязмалар бүлегендә саклана.

Ә.Фәйзи бәетнең 20 юлын «Тукай» романын язганда файдаланган[1]. Язучы тулы текстны Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә сакланган кулъязма җыентыктан күчереп алган булырга тиеш. Тукай яшәгән чорны сурәтләгәндә, язучы үзе җыйнаган материаллар белән генә чикләнеп калмый, ә бәлки Казан университеты, КФАНның әдәбиятчы галимнәре, өлкән буын язучылар белән очрашып, алардан файдалы фәнни киңәшләр ала. Моны архивлардагы рәсми кәгазьләр, әйтик, ТАССР Язучылар союзының 1949 ел, 30 апрелендә биргән белешмәсе дә раслый. Бу кулъязма җыентыкны шагыйрь Мәүлекәй Юмачиков, «Шәмсетдин Хөсәенов вәрәсәләре»нә бастыру өчен җибәргән була. Ләкин ул, нинди дер сәбәпләр аркасында, китап булып басыла алмаган. Хөсәеновлар фирмасы архивыннан Кәтиев дигән кеше аны университет китапханәсенә тапшырган. Ә.Фәйзи, «Тукай» романында тарихи-биографик әсәр буларак бик күп төрле социаль группаларны сурәтләгәндә, еш кына фольклор материалларына мөрәҗәгать иткән. Әйтик, романның I өлеш, 4 нче бүлегендә (65, 66 б.) «Эрбет бәете»н бик күп бәетләрне яттан белүче Сәхәби шәкерт кунаклар алдында көйләп бирә. 5нче

[1] *Фәйзи Ә.* Әсәрләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. — 2 т. — 65–66 б.

булектә (73, 74 б.) «Балкан сугышы бәете»н Ташъяк ярминкәсендә 1878 елгы рус-төрек сугышында имгәнеп кайткан карт солдат халык алдында жырлап йөри. Романдагы аерым персонажларны, татар халык тормышыннан этнографик күренешләрне, тарихи, дини, фәлсәфи моментларны яктыртканда да язучы халкыбыз гасырлар буе туплаган мәкаль-әйтем, табышмак, жыр, бәет-мөнәжәт кебек акыл жәүһәрләреннән оста һәм урынлы файдалана. Бәетнең сүзләре никадәр беркатлы, гади булып, көе аңардан да беркатлырак һәм зарыктыргыч булса да, ни өчен алар романда урын алганнар соң? Язучы жавапны үзе үк әсәрендә бирә (74б.): «Бу халыкның үз тормышын, үз язмышын кеше авызыннан икенче төрле итеп ишетергә теләве, кызыксынуы иде. Кызыксыну гына түгел, шундый сүзгә сусау иде бу. Дөрес, халык бу сусавын үз хыялында туган алдар таз, жиде башлы аждаһа һәм башка бик күп төрле әкиятләре, бәетләре һәм такмазалары белән басарга тырыша. Моның өчен аңа «Бүз егет», «Таһир-Зөһрә», «Йосыф-Зөләйха», «Былбылнамә» китаплары, Кисекбаш, Салсал һәм Сәет Баттал Газый кыйссалары, Хужа Насретдин мәзәкләре ярдәмгә килә. Боларны ул аз аңлаешлы төрек, гарәп, фарсы сүзләре аша сикереп аңларга тырыша. Гади халыкның күбесе бу китапларны укып аңлый алмый, алар берсе дә әле турыдантуры аның үзе турында түгел, бәлки хыялдагы илләр, вакыйгалар турында гына. Халыкның үзе турында, саф халык телендә сөйлисе, ишетәсе килә». Бу уңайдан «Эрбет бәете»нең теле шул чор халык бәйләм теленә якын. М.Юмачиков әсәрне гади кеше аңларлык, кабул итәрлек итеп язган. Текстта кайбер гарәп-фарсы сүзләре булу шул чор язма әдәбияты өчен гадәти күренеш. Укучыларга бәетне гарәп графикасыннан хәзерге татар язуына күчереп, текстологик эшкәртеп тәкъдим итәбез.

*Заһир Ислам,*
*филология фәннәре кандидаты*

# БУЛАТ СӨЛӘЙМАНОВ

*(1938—1991)*



*Булат (Бикбулат) Вәлиулла улы Сөләйманов 1938 елның 28 маенда Төмән өлкәсенең Вагай районы Сопра авылында дөньяга килгән. 1954 елда туган авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, башта туган авылында, аннан соң Тубыл, Салехард, Омск шәһәрләрендә төрле эшләрдә, төзелештә эшли. 1961 елда экстрен тәртиптә урта мәктәп тәмамлау турында аттестат алгач, 1962 елда Казанга килеп, Казан дәүләт университетына укырга керә. Аны тәмамламый, 1967 елда читтән торып Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институтында укый башлый. 1974 елда аны тәмамлагач, Себергә кайтып, башта Түбән Вартада, аннары Төмәндә язучылар оешмасының әдәбият пропогандалау бюросында эшли.*

*Булат Сөләймановның шигырьләре 1970 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Беренче карлыгачлар» җыентыгында басыла. Шунда ук 1980 елда «Таңнар фонтаны» һәм 1988 елда «Ак метеор» китаплары дөнья күрә. 1998 елда шагыйрьнең тууына 60 ел тулганда Екатеринбург шәһәренең «СП-96» нәшрияты аның «Мин — Себер татарымын!» дигән җыентыгын бастырып чыгара.*

* * *

Мин төп Себер татарымын чыгышым белән,
Гомер сөргән монда минем бабаларым.
Чал Иртышның үзе кебек, борынгыдан
Яшәп килә монда татар балалары.

Мин килмешәк түгел монда, туган җирем,
Гомерлеккә сине ташлап китә алмам.
Җирнең тарту көчен җиңдем, и Себерем,
Ләкин синең тарту көчең җиңә алмам.

## Самотлор

Йөзек кашы бит син Себернең!
Үзәгендә туган көмеш ай.
Астын өскә җирнең айка хет,
Сиңа тиңдәш күлләр юк бугай.

Бозлыклардан хасил булдыңмы?
Күктән иңгән сиңа күк төсе.
Әкиятләрдән әллә күчтеңме?
Себернең син сихри көзгесе.

Серле сандык серсез ачылсын,
Бар дөньяны, әйдә, сокландыр!
Киләчәккә синең күз белән
Туган илем карый, Самотлор!

## Түбән Варта

Парадмыни, тезелешеп
Йортлар кунган ап-ак карга.
Изүләрең җилгә ачып,
Ашыгасың кайсы ярга,
Түбән Варта?

Яшь бөркетләр каласы син,
Прописка юк «куяннарга».
Саз эченнән агып чыгып
Обька койган урамнарда
Ап-ак күбек.

Ә җилләре уттай салкын,
Исә борын заманнардан.
Кигән кием-толыбың да
Ап-ак йонлы бураннардан,
Түбән Варта.

Обь әйтерсең су үткәргеч,
Боз астыннан сулар ага.
Факелларда тандай ялкын,
Гомер җуйган тынлык яна,
Күктә яра.

Кабына да сүнә кояш,
Тынмый көрәш Самотлорда:
Буровойлар тишәр чорны
Иман барда, илһам барда,
Түбән Варта.

Девоннарга манып каләм
Бар бит эшләр башкарасы.
Үз тарихын яза бүген
Кар иленең башкаласы —
Түбән Варта.

## Самотлорда җәй уртасы

Түбән Варта, июнь ае.
Ә җилләре эттән яман.
Телә кемне[1] талап кала,
Кыш сулышын өрә һаман.

Инде айлап коя яңгыр,
Аяз көннәр була бик аз.
Ник көннәрнең күңеле бозык?
Аяк асты — болай да саз.

Машиналар измә изә,
Йөкне тизрәк ташыр өчен...
Самотлорда җәй уртасы —
Күргәнем юк җәйнең төсен.

Причалларда сезон өсте.
Тимер булып тимер өзелә.
«Вира», «Майне», «Давай тизрәк» —
Түзсә түзә кеше генә.

Баш өстендә кургаш күге,
Пресс сыман җанны сыга.
Эйфельмени, саз эченнән
Буровойлар үсеп чыга.

«Кирпеч барда салып калыйк» —
Манма суга баткан өйләр.
Яңгыр кебек саркып-саркып,
Шигыремә керә көннәр.

Керә көннәр, айлар, еллар,
Замананың төсен алып.
Буламы соң шундый чакта
Самотлордан читтә калып?!

[1] *Телә кемне* — теләсә кемне.

## Ак төн

Елмаеп, көлеп кенә
Язлар кабат килде.
Кышкы төннәр сагы —
Караңгылык үлде.

Әсәренеп баксаң
Тирә-якка әгәр,
Күз күреме җитә
Офыкларга кадәр.

Язның күнеле — гөлләр,
Тайга чәчәк атсын!
Йөзеп бара тауга
Ак бәхетле ак төн.

## Самотлорда туй

Түгәрәк күл тирәли юл,
Тимербетон җилкәсе.
Оператор кызга бүген
Балдак биргән иркәсе.

Икесендә ике балдак —
Кавышкан бармакларда.
Сөюләре
кулдән тирән,
Гаеп юк балдакларда.

Була ул
һәрбер сөюнең
Тәбриге,
алкышлары.
Самотлорда кунак түгел
Яшьлекнең аккошлары.

Киләчәккә кемнең барыр
Уллары, оныклары,
Себере булган халыкның
Киң,
иркен
офыклары.

Әкиятләрнең чынбарлыгын
Сөйли заман,
сөйләсен!
Самотлорны әйләнәләр, —
Теләсә кем әйләнсен.

Чаптар атлар кебек җилгер
«Жигули» да, «Волга»лар.
Ялларында төрле тасма
Һәм антенна —
колгалар.

Иң алдагы машинада,
(Ә аннан —
калганнары),
Егет белән кыз,
күзләрендә
Таңнарның фонтаннары.

Заманага, чорга тиңдәш
Яшьлек бизи юлларын.
Самотлорны түгел, гүя
Әйләнәләр җир шарын...

Түгәрәк күл тирәли юл,
Тимербетон җилкәсе.
Әйтерсең лә
Самотлорга
Балдак биргән иркәсе.

## Манси жыры

Юллар да минеке,
Кырлар да минеке;
Кырга җәелгән
Карлар да минеке,
Э-ге-ге-й-й.

Нарта да минеке,
Таннар да минеке;
Нартага җиккән
Аннар[1] да минеке,
Э-ге-ге-й-й.

Хорей[2] да минеке,
Бу кыш та минеке;
Күккә эленгән
Кояш та минеке,
Э-ге-ге-й-й.

Тайга да минеке,
Тундра да минеке;
Кошлар, җәнлекләр —
Барсы да минеке.
Э-ге-ге-й-й.

Барсы да минеке.
И туган илем,
Э-ге-ге-й-й.

---

[1] *Аң* — Себер татарлары телендә «болан» дигән сүз.
[2] *Хорей* — нартага җигелгән боланнар белән идарә итү таягы.

## Төньяк, тундра

Төньяк,
Тундра,
Поляр төннәр.
Карангылык хакимлеге,
Иксез-чиксез кар иле бу,
Монда дөнья иркенлеге.

Даламыни,
Җәйрәп ята,
Ник очрасын хет бер агач.
Яңа туган бала кебек,
Бу кар иле —
шыр ялангач.

Җилләр йөри кар себереп,
Йә кинәттән чыга буран,
Ак күбекләр күккә чөйгән
Диңгездәге давыл сыман.

Кояш офык аръягында,
Күренмидер нур чаткысы.
Киләчәккә өмет сыман
Сүнми бары
кар яктысы.

Сукыр көннәр,
Сукыр төннәр...
Минем дә бит
Андый көннәр бар иде.
Әй кар иле,
кар иле.

## Сопра[1]

Бөтен Себер буйлап,
Орлык кебек,
Татар авыллары сибелгән.
Гасырларнын
Изге туфрагына
Тамырлары
Тирән кумелгән.
Исемнәре
Читтән кергән тугел:
Баеш,
Рәнцек,
Меткә,
Киндерле...
Шулар арасында
Минем Сопра да бар —
Туфрагында
Безнең Себернең.
Ул һаман да
Сопра булып яши,
Юкса
Купме дәвер узылган.
Беркем белми,
Шундый сәер исем
Каян алып,
Нигә кушылган?
Яулар килгән,
Илләр алышынган,
Алышынмаган
Ләкин
Бу исем.
«Алышынмадым,
Юк,
Алшынмам мин,

[1] *Сопра* — шагыйрьнең туган авылы.

Тамырларым
Минем нык, — дисең. —
Сопра түгел,
Аның исеме белән
Туган илем
Үзе эндәшә».
Мин бер улы аның.
Ишетегез!
Киләчәккә
Бүген мин дәшәм:
Сопра булып
Сопра калыр әле,
Иртыш таллары да
Ул уйда.
Һәр ел саен
Иген батырлары
Мәйдан тота
Сабан туенда.
Мәйдан тота
Ирләр,
Яшьләр бергә,
Туган туфрак икән
Нык терәк.
Тамашага
Аксакаллар килгән,
Уйларында бары
Бер теләк:
Атлар сыман җирсеп,
Бер мәйданга
Җыйналырбыз әле,
Кем белгән.
Орлык кебек,
Бөтен Себер буйлап
Татар авыллары
Сибелгән.

## Тобол

Октябрьга чаклы
Россиядә
Төрмәләре белән дан тоткан
Иске Тобол,
Бүген күкрәгендә
Яңа йортлар күккә калыккан.

Тын Себергә синнән
үткән чакта
Декабристлар каны түгелгән.
Тобол, Тобол,
Бүген ярларың
Гөлчәчәкләр белән күмелгән.

Ничә гасыр, әйтче,
Ничә гасыр
Мәхрүм булган халкың иректән.
Ә син Тобол,
Гүя үсеп чыктың
Каторжаннар яткан җирлектән.

## Көзге урманда

Уйга талып басып торам
　　　　　　берьялгызым.
Көзге урман
　　　охшап калган каберлеккә
Минем күңелем сыман моңсу
　　　　　　агачларда,
Алар
　　　шулай калыр төсле
　　　　　　гомерлеккә.
Кошлар да бит
　　　ташлап киткән
　　　　　　бу урманны.
Болытларга кереп баскан
　　　　　　якты нурлар.
Рәхим-шәфкать сораган күк
　　　　　　Аллалардан.
Тырпаешып тора бары
　　　　　　шәрә куллар.
Үткән гомер
　　　безгә кире кайтмаган күк,
Язлар кире кайтмас төсле
　　　　　　бу урманга.
Агачларның җирдә ята
　　　　　　йөрәкләре.
Күпме яфрак үлгән
　　　кайгы саргайтканга.
Ләкин
　　　язлар тагын килер,
　　　　　　килми калмас!
Табигатьнең үзенең бар кануннары.
Күңелемдә
　　　истәлекләр генә минем.
Ә урманга
　　　мәңге яшьлек
　　　　　　тамырлары.

**Китүләре бигрәк авыр икән**

Ерак юлга чыгып китүләре
Авыр икән
туган җиреннән.
Әй Иртышым!
Эчкән суларым да
Кипмәгәннәр әле иренемнән.

Сине сөюем,
Сине сагнуларым
Биләделәр минем күңлемне.
Әй Иртышым!
Синең ярларыңда
Сыгылып үскән таллар дисеңме, —

Бар да,
Бар да минем йөрәгемдә
Үзләренә урын алганнар.
Ак калфаклы
шаулы дулкыннарың
Җырларыма кереп калганнар.

Күзем йомсам
Күрәм тугайларың,
Тугайларга төшкән чыкларың.
Шул чыкларны ерып
Сукмак салган
Таңнарымны истә саклармын.

Әй Иртышым!
Синнән китсәм дә мин,
Гомерлеккә ташлап китмимен.
Йөрәк түгел,
Гүя дулкыннарың
Кага кебек күкрәк читлегем.

* * *

Кыр казлары үтте каңгылдашып,
Сагышларын күңелем бүлеште.
Авыр икән канат кагулары —
Дулкынланып калды күл өсте.

Мин дә китәм...
Ниләр көтә мине
Туган җирдән читтә, еракта?
...Бүген тагын күз яшьләре күрдем
Торып калган ялгыз яфракта.

## Мин бер серле

Син тугансың
Минем йөрәгемдә,
Мин туганчы
Газиз анамнан.
Себер! Себер!
Бер син генә җирдә
Минем мәхәббәтем
Казанган.

Җаным кебек
Бик кадерле миңа
Туган җирнең
Изге туфрагы.
Бу дөньяда
Себер агачының
Мин бер серле,
Моңлы яфрагы.

## Казанга

Казан!
Себер тикле Себерләргә
Ишетелде якын моңнарың.
Искән җилләр
Алып килде аны,
Бураннарда бәүлеп[1] тыңладым.

Аннан аны
Иртыш дулкыннары
Көйләделәр юып ярларын.
Кая барсам,
Җырлап озаттылар
Иксез-чиксез ап-ак карларым.

Сунардаш күк дус та була белде,
Тайгаларда ауда йөргәндә.
Синең моңны көйләп
Тост күтәрдем,
Дусларыма шәраб биргәндә.

Туган җирем мине ир булырга,
Чигенмәскә юлда өйрәтсә,
Синең моңнар миңа
Канат бирде,
Җыр уятты кыргый йөрәктә.

Күңелемдә эретеп салкыннарын,
Ярсуларын алып давылның
Зәңгәр күккә чөйдем,
Җырга салып,
Сагышларын туган ягымның.

---

[1] *Бәүлеп* — Себер татарлары сүзе — «тирбәлеп», «калкып» дигән мәгънәдә.

Синең моңнар мине алып килде
Бишегенә татар халкының.
Ничек кенә язмыш сынамады,
Сүрелмәде ләкин ялкыным.

И Казаным!
Туган анам кебек,
Кочагыңа ал син гомергә.
Ярсып чапкан
Минем чал Иртышым
Кушылып аксын синең Иделгә.

## Толымбай[1]

*Зенфирага*

Күктән йолдыз тотмыйм,
Шигырьләрем
Хатыннар күк йөртеп тутырам.
Менә бүген
Күңелем буранында
Толымбайны уйлап утырам.

Мин берүзем
Уйлар буранында,
Уйларымны сүтәм,
яңартам.
Дөнья буйлап
Чабып йөримен дә
Толымбайга кайтам яңадан.

Чал чәчләрен йолкый
Җилләр кышы,

[1] Татарстанның Буа районындагы авыл.

Каеннарның толымын сагынган
Аллаларга түгел,
Бик борыннан
Толымнарга ирләр табынган.

Кай болынны урдең толымыңа?
Кай туфрактан шыттың
Толымбай?
Йөрәгемнең
Чәчкә үрелгәнен
Бүген яна белдем,
Йә Ходай.
Толымсыз кыз
Тол хатын кук ялгыз.
Күзгә таллар кебек
шәп-шәрә.
Син булмасаң илдә
И Толымбай!
Булыр идем
мин дә
Мәсхәрә.

Кайсы кызда бүген
Бар соң толым.
Сорасалар миннән,
ни әйтим.
Син булмасаң җирдә,
И Толымбай!
Илсез,
җирсез,
синсез.
Мин ятим.

## Иделдә

Иделдә йөзгәндә
Илкәем буйлап, мин
Болгарга тукталмый
Һич кенә үтәлмим.

Килгәндә, күнелдә
Мең төрле уй иде.
Туктадык: ялан яр,
Бу — Болгар бит инде.

Сак кына атладым,
Иң изге җир бит бу.
Хәтердән җуелмый
Сакланган җыр бит бу.

Бер агай сорады:
«Болгарда кемең бар?» —
Тын калып иелде,
Ни әйтсен дигәндәй,
Кылганнар...

* * *

Уйный җилләр нинди кылларда
Үзләренең кыргый көйләрен?
Ул көйләрдә
Ерак нәселемнең
Чакыруын ишетә йөрәгем...

Төннән баккан
Ерак йолдызлардай,
Күз алдымда яна учаклар.
Учак тирәсендә ярым кыргый
Халык —
йә скифлар,
йә кыпчаклар.

Сузып-сузып нидер көйли алар,
Кысыграк күзле азиатлар.
Дер селкетеп
Бөтен Европаны
Дала буйлап чабалар атлар.

Телләре дә гүя
Таныш кебек,
Ул телләрдә, димәк, җырлегем
Нәселемнән

Күчеп килә миңа
Күк-тәрәзәм,
йорт —
җир минем.

## Әйтмәгез Себерем хакында

Бүлмәмдә саф нарат исләре,
Гомергә иснәп тә туймамын.
Үзләре артыннан ияртеп
Бүлмәдән чыгара уйларым.

Уйларым артыннан чабам мин,
Тышаудан ычкынган ат сыман.
Тоболга сугылмый үтелсә,
Үземә мин үзем ят сыман.

Әйтәсез
«Үткәнгә кагылма,
Кыен ул хаклыкны аңлавы».
Баш куеп тыңлагыз,
Бу җирдән,
Ишетелер богаулар чыңлавы.

Йөрәгем аркылы кичерәм
Дәверләр,
гасырлар тавышын.
Бөртекләп җыйган күк,
Җыям мин,
Халкымның шатлыгын,
сагышын.
Әйтмәгез!
Себерем хакында!
«Үткәндә каргалган җир булган».
Каргалса каргалсын,
аңлагыз,
Ул минем туган җир,
И туган!

* * *

Куптәнме җәй иде,
Казанга
Кыш инә күкләрдән ишелеп.
Ду килеп йөримен урамда,
Карларның исеннән исереп.

Күңелемдә мең дәрья,
Чиксезлек,
Урамнар әйтерсең тарлавык.
Төн кызый —
Ул минем кочакта,
Алкышлар сибелә кар булып.

Кыш инә Казанга,
Ак карлар,
Пакь карлар сабый күк сөйкемле.
Күкләрдән
Тагын да ишелеп
Нәрсәдер явырдыр шикелле.

Бу төндә
Шәфкатьсез гүзәллек
Бу төндә
Тылсымлы шигърият
Төн кызый —
Тилергән йөрәгем —
Кайларга илтәсең сихерләп?

Муенга сарылып ут әйтте:
Син тиеш хәлемне аңларга,
Мин үлсәм үләрмен,
Тик сине
Таңнарга илтәмен,
Таңнарга.

* * *

Мин ялгызым йөрим урамда,
Бар да таныш,
Бар да ят монда.

Чал Себердән Казан каласына
Кемне эзләп килдең, йөрәгем?
Салкын җилле бураннарың белән
Кемгә бар соң синең кирәгең?

Йортлар гүя бармак янап кала:
Күрмәгәнең монда күрерсең!
Төнге утлар канат кагып көлә:
Әй, адашкан!
Нишләп йөрисең?

Урам буйлап тагын алга үтәм.
Әнә мәйдан...
Тагы алгарак...
Кара плащ ябынып шагыйрь тора, —
Таш һәйкәлнең киләм янынарак.

Күз карашы аның һаман гашыйк,
Ул Казанын сөеп туймаган.
Хисләренең тирән, кадерлесен,
Моңлы сазын шунда уйнаган.

Кара плащ ябынып шагыйрь тора,
Учы белән тоткан йөрәген.
Мин китердем аңа
Чал Себернең
Күкрәгендә шыткан гөлләрен.

Мин ялгызым йөрим урамда,
Бар да таныш,
Бар да ят монда.

* * *

Күренәме Себер Казаннан?
Анда карлар, җилләр уйныйдыр.
Ә тайгада болан баласы
Адашкан да ялгыз, елыйдыр.

Хет җилләре хәбәр бирсәче:
Ничәнче көн эзли анасын?
Аерылу авыр кемгә дә,
Тайга киң шул, каян табасың!

Эзләреннән бүре киләдер,
Борылыр да иде кирегә,
Юк, ярамый, алга ыргылды,
Бала чагын калдырып бүрегә.

Шулайдыр ул хәлләр минем дә,
Эзләремне карлар күмидер.
Адашкан да тайга эчендә,
Бала чагым елап йөридер.

## Тукай кабере янында

Бүген
      кояш
            кайнар яшен түгә.
Яз.
Урамнарда карлар
Кемне сугә?
Менә
      аның кабере.
Кара мәрмәр таш,
Тимер рәшәткәләр,
Тел әйләнми,
            әйләнә баш.
Туктый хәрәкәтләр,
                  чардуганнар
Сүзсез
Иелгәннәр түбән.
Ак кар,
      пеләш,
            бөдрә башлар...
Бер сүз дәшми,
                  елый
Кара таш кабер.
Гүя анда
      Кеше
            жаны бар,
Өзгәләнә
      нигә
            бу бәгырь?!

**Кичен. Аккош күле**

Кичен.
Аккош күле.
Яшь бер егет
учак яга
Яшьлек бакчасында.
Күктән
Йолдызларны өзеп
Утка сала —
Мәхәббәтне...
Көннәр,
айлар яна.
Дөрли-дөрли
Күккә үрли
Ялкын.
Нәрсә аңа,
Барсы әле алда.

Күршесендә
Бик мөлаем бер карт,
Ул да
учак яга,
Гомер бакчасында.
Ашыкмыйча,
әкрен генә
Чал чәчләрен сыйпап ала,
Коры-сары җыеп өсти,
Өреп карый.
Ә учагы
никтер
янмый —
Үле.
Янмый —
Үткән гомер көле.

## Мин кайтырмын

Яшәсәм дә Тукай Казанында,
Йөресәм дә Идел ярында, —
Туган җирем
Себер кочагына,
Бер кайтырмын әле тагын да.

Тормыш үзе миңа белем бирә
Тайгаларда юллар салырлык.
Ә син, җырым,
кайтма Себеремә,
Булсаң әгәр
Буранында күмелеп калырлык.

## Казаннан китәр алдыннан

Үткән көннәр кайтмаса да,
Хәтерләрдә көле кала.
Кайгыларым, сагышларым
Мул бирдем мин,
Казан кала.

Үпкәләрсен дип уйламыйм,
Йөрәгенә барсы сыяр.
Идел,
Кабан буйларында
Төннәремнең яктысы бар.

Сүз кирәкми,
бар да калсын
Үткән көннәр файдасына.
Китәм сабый җаным алып
Ялгызлыкның Тайгасына.

Казандагы топольләргә
Себер җиле хәбәр иткән.
Мин утырткан каенкаем
Мине сагынып җырлый икән.

Рәшә түгел, мираж түгел,
Әллә минем Сопра микән?
Иртеш ага күзләремдә
Тел төбемдә суы кипкән.

Бәлки, әле сүнмәгәндер
Ягып киткән учагым да.
Атлар кешни төшләремдә —
Төнге болын кочагында.

Бәлки, мине көтә булыр
Тын күлләрнең аккошлары,
Болыннары,
урманнары,
Яфракларның алкышлары.

Ак нурлары юлларымда,
Анда көтә мине таңнар...
Саубуллашмый китәм, Казан,
Җырларымның киләсе бар.

# ШӘҮКӘТ ГАДЕЛША

(1949)



*Шәүкәт Гаделша (Сибгатуллин Шәүкәт Гаделша улы) Төмән өлкәсенең Түбән Тәүде районы Киндерле авылында туа. Авыл мәктәбен тәмамлагач, электрик һөнәрен үзләштереп, башта Төмән өлкәсендә, аннары Татарстанга килеп, Чаллы шәһәрендә төзелештә эшли. 1973 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1977 елда читтән торып уку бүлегенә күчеп, туган якларына кайтып, авыл хуҗалыгында эшли башлый. Шигырь җене кагылган, югары шигърият белән илһамланган егетне шагыйрьләре, әдәби тормышы белән кайнап торган Казан үзенә тарта, 1980 елда ул кабат Казанга әйләнеп кайта, укуын тәгәлли, «Агитатор блокноты» журналында әдәби хезмәткәр булып эшли башлый.*

*Шәүкәт Гаделша берничә шигъри җыентык авторы. 2004 елда Татарстан китап нәшрияты аның күпьеллык иҗат җимешләрен туплаган «Аучы җыры» исемле саллы китабын бастырып чыгарды.*

## Сазлык

Мулла бабам куылганда
Алтынын күмгән, имеш.
Чалдон бабам ачтан үлгән,
Камыш чәйнәгән килеш.

Болай да суык көз көнен
Суыта алтын төсе.
Кабыргама охшый камыш, —
Сөяк шакылдый төсле.

Сәер тынлык, упкын булып,
Мине суырыр кебек.
Әллә нинди олы җаннар
Сикереп торыр кебек,

Елар алар үкерешеп,
Акылдан яздырганчы.
Мине ямлап талашырлар,
Йөрәгем ярылганчы.

Мондый сазлар берәү микән,
Күп микән? Кемнәр белә?
Бәхет басармы халыкны
Шундый сазлыклы илдә?

* * *

Ботаксыз наратны
Бик дәртләнеп
Чукый тукран.
Ә мин сөйгәнемне
Җырлар җырлап
Көтеп утырам.

Икенче агачны
Бик тырышып
Чукый тукран.
Ә мин сөйгәнемне
Бик сагаеп
Көтеп утырам.

Өченче агачны
Тыз-быз килеп
Чукый тукран.
Ә мин сөйгәнемне
Кайгы йотып
Көтеп утырам.

Нигә соң килми ул,
Нигә һаман
Ялгыз утырам?
Агачларны түгел,
Йөрәгемне
Чукый тукран.

* * *

Авылдашларым җылым тарта,
Күл буена җыйналып.
Кулларымны тыгып кесәгә,
Читтә торам, оялып...

Урам уртасыннан каршыма
Килә авыл картлары.
Кулларымны тыгып кесәгә,
Тар тыкрыкка атладым...

Зәңгәр күзле сабый чирәмдә.
Эх! Башын сыйпап үтәргә!
Кулларымны тыгып кесәгә,
Сөялдем мин киртәгә...

Нишләргә? Куллар шома, хәлсез,
Үлгән чабак төсендә.
Шундый куллар белән кайтканны
Монда халык чит итә.

* * *

Улы карт анасына хат язды:
«Әгәр көннәр артык кызу булса,
Кара көйсә, шиңсә һәр ягың, —
Җыяр идем, әни, синең өчен
Аккошларын бөтен дөньяның.

Очар иде алар баш очында,
Тезелешеп, салмак тирбәлеп.
Кочар иде сине, назлар иде
Ак канатның йомшак җилләре.

Әгәр көннәр артык салкын торса,
Төбе катса тирән Тоболның, —
Җыяр идем, әни, синең өчен
Төлкеләрен туган ягымның.

Туннарыннан иркен чатыр ясап,
Яшерер идем сине җилләрдән.
Шул җылыга, әни, җырчы кошлар
Килер иде ерак илләрдән...»

Ялгыз ана кыска җавап язды,
Күз яшенә хатын чылатып:
«Ишектәге тотка төште, улым,
Каксаң иде шуны бер кайтып...»

### Тундра кызы җыры

Ак тун кигән кыз ак нартада.
Хорей[1] болытларга орына.
Чапкан боланнарга дәрт өстәп,
Ненец кызы суза җырын да:
— Эhe-hей-hей!

Бушлыктан соң үрләр артында
Тук боланнар күкне сөзәдер.
Үрләрдән соң бушлык артында
Яшь боланчы мине көтәдер.

Аламыйдыр күзен офыктан,
Керфегенә кырау кунгандыр.
Кар астында яткан чиядәй,
Иреннәре аның туңгандыр.
— Эhe-hей-hей.

Очыйк-очыйк, боланнарым, hей!
Тетрәсен, күкрәсен тундрам.
Узып китик салкын кояшны,
Сөйгәнемә кояш — мин булам.

---

[1] *Хорей* — болан куа торган озын таяк.

* * *

Сердәшләр булганга,
Мин йөрим урманда.
Кычкырам бар көчкә
Сулга да, уңга да.
Яшьлегем, син нинди?
Төсләрен күренми,
Яшьлегем, син кайда, —
Яшердеме тайга?

Агачтан агачка
Сикерә бер тиен.
Белмәссен, шул тиен —
Яшьлегемдер минем.

Каенда бер кошчык
Сайрый да, бии дә.
Ак зифа каенның
Башкае иелә.
Ник җырлый, ник бии?
Күтәме үз тиңен?
Белмәссен, шул кошчык —
Яшьлегемдер минем...

Тырышып-тырышып
Йөгерә кырмыска.
Оясы еракта,
Аягы бик кыска.
Төртә, йөгертә
Үзенең зур йөген.
Белмәссен, кырмыска —
Яшьлегемдер минем.
Чайкала үләндә
Шат чыклар дингезе.

Һәр чыкның күзендә
Күрәм мин күк йөзен.
Юк итте диңгезне
Итәге шук җилнең.
Әллә соң шул чыклар —
Яшьлегемме минем?

**Балык шулпасы**

Күл буенда учак яна,
Кыл-казанны тирбәтеп.
Авылдашлар кыстый мине,
Әйдә, берне җибәр, дип.

Эчкән идем бер тустыган, —
Яктырды күз алларым!
Күз кысалар чәчәкләре
Аргы як аланнарның.

Туймадым мин, тагын эчтем, —
Тәнемә йөгерде дәрт.
Йолкып ташлый күрмәсен дип,
Нарат тора дерелдәп.

Өченчене эчкән идем,
Хисләрем чиктән аша.
Җырлап җибәрер бу, дип,
Якташлар пышылдаша.

Исердем бит! Миңа рәхәт!
Оҗмахка кердем кебек.
Бәдәннәре дерелдәгән
Карт идем — булдым егет.

## Аучы жыры

Мәче кебек
Мырлый урман,
Чаңгыларда
Басып торам.
Мылтык иңгә
Жылы бирә.
Жил көпшәгә
Моңын өрә.

Белдегезме:
Мин — сунарчы,
Сусар атам
Көн узганчы.
Алда бәйрәм
Көтә мине —
Сөйгәнемнең
Туган көне.

Ниятемне
Әйттем иртән.
Көмеш бүрек
Бүләк итәм.
Атмый кайтсам
Әгәр бүген,
Чынлап сөйми,
Йә син, йә мин.
Шикләнмәскә
Кирәк, дидем;
Миндәй мәргән
Сирәк, дидем.
Кар очкыны
Чага күзне;
Күрү кыен
Кирәк эзне;

Сусарым да
Ерак киткән;
Кайсы төпкә
Туктар икән?

Бүген аны
Табалмасам,
Күзгә төбәп
Аталмасам,
Әй, сөйгәнем,
Җаным-иркәм,
Янына мин
Якын килмәм.

Көн яктысын
Каплый болыт,
Ишелә күк
Ак кар булып.
Ак кар күмәр
Сусар эзен;
Адашырмын,
Бәлки, үзем.
Нигә бу көн
Киреләнә?
Сөюемне
Белми мәллә?
Әллә иркәм
Сөйми микән,
Минем кебек
Көйми микән?
Менә төн дә
Килеп җитәр.
Көн яктысы
Карга сеңәр.
Тәнем манма
Тиргә батты.

Чаңгыларга
Бозлар катты.
Сусар эзе
Ерак киткән.
Кайсы төптә
Туктар икән?
Ялга чуксәм,
Тора алмам.
Җәзамы бу —
Булмый аңлап.
Әллә кыз да
Минем кебек
Сөя микән
Янып-көеп?
Булыйм диеп,
Кыйбатрак,
Кача микән
Сусар ерак?
Әллә җәнлек
Сыный инде
Кызны ничек
Сөюемне...

Бара торгач,
Эз югалды.
Иптәш булып
Тик төн калды.
Мин төрлечә
Төнне сүктем.
Үкси-үкси
Әйттем сүзем:
«Нигә мине
Харап иттең?
Сусарыңны
Карак иттең?»
Бәхетемне
Урлап качты.

Күз яшьләрем
Кайнар, ачы.
Бүре кебек
Улап карыйм.
Мылтык атып,
Елап карыйм.
Коелмый төн!
«Сусар, сусар!» —
Елый чаңгы,
Сызлана кар.
Язар идем
Акылдан мин;
Күрәм йолдыз
Атылганын.

Төшкән чакта
Балкып алды,
Нигә миңа
Кадалмады?
Үтергәнче
Кадалмады...
Хәлләремне
Аңламады...
Авылга ул
Сугылгандыр,
Тәрәзәләрдә
Сызылгандыр.
Җан сөйгәнем
Курыккандыр,
Уе минем
Турындадыр.
— Әйдә, шуыйк,
Чаңгыларым,
Өйгә кайтыйк
Таң туганчы.
Ә сусарны
Бүтән кумыйк.

Сөйгәнемнән
Бүләк булып
Калсын әйдә
Туар таңга,
Булсын бүләк
Карурманга.

Сусар да пар
Тапкандыр ла;
Шуңа оста
Качкандыр ла.
И сусаркай,
Өметтәшем,
Шаһитлыкка
Сине дәшәм.
Озатып бар
Син алдымнан.
Сиңа бер дә
Мин кагылмам.

Чаңгыларым
Пышлашалар;
Сусар белән
Хушлашалар.

Белдегезме:
Сунарчы мин.
Төн узып көн
Туганчы, дим...

## Таңын ауда азан ишеттем

Төнен берни булмагандай
Жайлап кына кызара таң.
Кайсы авылдандыр? Ага
Жылы бөркеп моңлы азан.

Нинди тылсым алыштырды
Тирә-юньнең манзарасын?
Чыршы тора, әйтерсең лә
Яңа мәчет манарасы.

Серле энгерлеккә чумган
Куакларны, ботакларны
Коръәндәге хәрефләргә,
Сүрәләргә охшатамын.

Укырга дип көчәндерәм
Күзләремне, миләремне.
Онытканмын тумышымнан
Надан, динсез икәнемне.

Айкый азан күңелемнең
Булган бөтен тирәнлеген.
Җиргә сугып ватмак булып,
Мылтыгымны кизәндем мин.

Тонык кына яңгырый азан:
«Яңа заман, яңа заман!»
Ә мин, бүре баласыдай,
Караңгылыкка карыйм һаман.

* * *

Язмышымның дәрьясы —
Казан, Төмән арасы.
Иңнәргә очкан кошның
Канаты мең арасы.

Кайсы сазлык суырган
Сукмагын бабамнарның?
Каенда — сөяк төсе
Күмелеп калганнарның.

Кайсы ягына карап
Минем бабам елаган?
Көнбатыш та, көнчыгыш,
Башка яклар булмаган.

Кыпчакмы мин? Монголмы?
Каһәр суккан татармы?
Кайсы якка кайтам да,
Кайсы якка барамын?

Кайсы якта черегән
Ыруымның казыгы?
Яшьнең иң гөнаһсызын
Кайсы якка агызыйм?

Казан, Төмән арасы —
Мәгънәм минем, канатым.
Эх, үлеп булса икән,
Бар буена капланып...

* * *

Урман шәрә, җил тундыра,
Көттерә кары.
Куянның тун алыштырып
Алданган чагы.
Туң чокырда йомарланып
Калтырый мескен.
Аучы өскә килмәсен дә
Тизрәк көн үтсен.
Сызлый башы, колак, койрык,
Кысып ятудан.
Кузгатсалар, кая качар
Төбәп атудан.
Сукаланган кап-кара кыр
Кая карама.
Аксыл төсләр чакрымнардан
Күзгә кадала.
Йөгергән куянны күрер
Берничә авыл.
Аучы җене кагылганнар
Чорнатып алыр.
Нигә быел ак карлары
Озак көттерә?
Шәрәлектән башкаема
Төрле шом керә.
Үзем ак ниятләр булып
Шартларга торам.
Заман гына кара төстә, —
Шуңардан куркам.
Мин кемең дип, халкым, нигә
Уйланып торам;
Ашыгып тун алыштырган
Куяның булам.

## Поши аткач

Шундый салкын. Нарат шартлый.
Эт селәгәе боз булган.
Жан чыгарып яткан поши
Җылысына сыенам.

Карт аучылар ашыгалар —
Пычаклары йөгерә.
Сунарчымы? Үтерүчеме? —
Үземне кем дияргә?

Ирексездән сораусынып
Текәләмен Галәмгә.
Аң көчәнә — динсезлегем
Алланы эзли мәллә?..

Карт аучылар сөяк чаба —
Өлешләргә бүләләр.
Итне түгел, гүя күчләп
Гөнаһларын өяләр.

И табигать, нишлим инде?
Алам миңа тиешне.
Бабалардан калган гөнаһ —
Өлешемнен кәмеше.

Картлар йөзе шундый кырыс!
Куркамын эндәшергә.
Шул кырыслык бик борынгы
Күңелсез сер яшергән.

Җылынмый көн. Нарат шартлый.
Үзәндә — аксыл томан.
Үр артында, күпләп атып,
Поши туныйлар сыман.

Шумый юкә чаңгыларым —
Табаннарга кан каткан.
Эзәрлекләп гомерлеккә,
Авыр хис кайта арттан.

### Яңа уй

Дәһшәтле чытырдап,
Учак талпына:
Яшь Себер татары
Ята янында.

Өр-яңа уй уйный
Егет аңында.
Серле дәрт гөлтләнә
Тубыл талында.

Кояш та үтәли
Баккан учакка;
Күләгә дөньясын
Урый-чуалта.

Егетнең уй-хисе
Очкын очыра, —
Себернең тарихы
Бүген борчыла.

Дулкыннар очлана,
Калкып тирәннән, —
Әйтерсең Ермакның
Шлемын кигәннәр.

Һавада сызгыра
Уклар өере.
Атларны, гаскәрне
Үтте йөгереп.

Корыган наратлар
Шартлап авалар,
Әйтерсең казаклар
Туптан аталар.

Ә егет ишетми —
Чумган уена.
Ялкыннар, сөенеп,
Аңа сыена.

Камышка, талларга
Дәһшәт урала.
Яңа җыр-тантана
Бүген ярала.

Иң татлы, иң изге
Көчәнеш иңә:
Ирнең дә, җирнең дә
Елыйсы килә.

Ә козгын, карт козгын
Нигә очмый соң?
Наратка сыенып
Нәрсә уйлый соң?

Егетнең уенда
Уйный очкыннар:
«Бу җирнең хуҗасы —
Мин бит чынында.

Бу җиргә иң тәүге
Тир, яшь, кайнар кан,
Ерткычны куркытып,
Тамган бабамнан.

Беренче учакны
Монда ул тергезгән.
Авазны сүзләргә
Башта ул төргән.

Өшегән, ысланган,
Баткан, югалган, —
Кешене кыргыйдан
Саклап калалган.

И табигать улы —
Самим бабам!
Зинһар, гафу ит.
Сине кызганам.

Аллабыз нигә сон
Сакчың булмаган?
Ни гөнаһ өчен сон
Коллык юллаган?

Явызлык, комсызлык
Сине ник җиңгән?
Урманны, сазларны
Читлек иттергән.

Кем әйтә: «Ризалык...», — дип,
Бу бит — түземлек.
Һаман да яшикме
Рәнҗеп, кимсенеп?!»

Сикрергә җыенган
Бүре шикелле,
Ялкыннар, сыртланып,
Җиргә иелде.

Ә козгын, карт козгын
Нигә очмый сон?
Наратка сыенып
Нәрсә уйлый сон?

Сөрелгән килмешәк
Бүген узына, —
Монда мин хуҗа, дип
Күкрәк сугына.

Бу жирдә бу егет
Бар дип уйламый.
Тоеп жир рәнжешен,
Каны еламый.

Болытлар, камышлар
Таллар, каеннар —
Бар жиһан тартыла
Учак янына.

Дәррәү кабынып, бер
Балкып алырга,
Күкләргә айкатып
Сөрән салырга.

— И Алла, егеткә
Индер көч-куәт.
Килмешәк нәфесен
Тыйсын хакыйкать.

Шаһит бит Жир-ана,
Шаһит — син, Аллам.
Бу төбәк — төп мирас
Калган бабамнан.

Гайрәтле гөрелтәү
Очкын очырта:
Әллә ул искәртә,
Әллә котырта?

— Бу жирдә иң әүвәл
Бабаң таш алган.
Ерткычка иң әүвәл
Ул бит ташлаган.

Карт козгын селкенеп
Куйды кычкырып.
Өзелде егетнең
Уйлар чылбыры...

Мылтыгын төзәде
Козгын башына.
«Атарга ярамый!» —
Күңел ачына.

Козгынны атарга
Кушмый бит картлар.
Нигә соң бу коштан
Алар куркалар?

Буыннан буынга
Күчкән бу тыю.
Йоланы бозмакчы
Егетнең уе.

Карт козгын очмады,
Бүген көн озын.
Наратка сыенып
Нәрсә уйлый соң?

Сугамы ялкыннар
Кара йөзенә?
Керәме төтеннәр
Комсыз күзенә?

Уйлыймы: «Бу җирдә
Ермак чорыннан
Никадәр татарның
Башы чукылган».

Җилләргә ябыша
Учак егәре:
Кучермәк була күк
Җирне, күтәреп.

Кайтырга ашыгам.
Көт мине, якташ.
Сүнмәсен учагың, —
Булам учакташ.

## Черкине сагынам

Күлсәгез күләрсез, дусларым,
Бу сәер чагымнан.
Себернең мәчкәен — тынгысыз
Черкиен сагынам.

Бу — чирме? Ни булса, шул булсын —
Күчкәндер бабамнан.
Черкиләр тешләгән тәнемне
Кашудан тәм табам.

Черкине тыңласам, тынлыкта
Оета тирән моң.
Хәтерем урманын, күз йомып,
Үтәләй күрәмен.

Зур хаким йә мескен хәлендә
Үземне хис итәм.
Черкиләр безләвендә вакыт
Агышын ишетәм.

Черкиләр тәнемә, йөземә
Ярарып кадала.
Куанам, димәк ки, тамырдан
Сәламәт кан ага.

## Себер татары

Ишкәгемне киң каерып
Тирән батырамын.
Көймәдәшкә җиңел була
Ишеп барулары.

Учак яксак, чүмәшәмен
Очкын очкан якка.
Учакташым төтен йотмый —
Җайлап кына ята.

Киек атсак, үзем сорап
Алам кабыргасын, —
Итләрәге миңа түгел,
Сунардашка калсын.

Бирәм соңгы серәнкәне[1]
Соңгы телемемне.
Күрәм кеше күңелләрен,
Тыңлап күңелемне.

Кызганмыйм да, үкенмим дә —
Рәхәтләнеп калам.
Себер татарларын шулай
Яраткан бит Аллам.

---

[1] *Серәнкә* — шырпы.

## Нинди Төмән?

*Булат Сөләйман истәлегенә*

Иркен Төмән!
Монсу Төмән!
Юмарт Төмән!
Кызу Төмән!
Минем Төмән — Туган ягым капкасы!
Куыштырып дулкыннарын,
Елгыр Тура[1] сорый миннән:
— Сагыныпмы, кызыгыпмы кайтасың?

Монда болгар,
Монда монгол,
Монда үзбәк,
Казахыдыр,
Монда манси[2] — буталганнар каннары.
Аталабыз — Себер татарлары,
Әмма кайсыбызның
Бабалары чып-чын Себер татары?

Тарих тирән,
Кое сыман:
Мүкле, серле,
Төшкән саен
Салкынрак, куркынычрак тоела.

Телим кайчак
Мәрхүм әкәм
Булат кебек
Кайберләргә:
— Сез — килмешәкләр, — дип әйтеп куярга.
Кайчагында,
Күнелләнеп:

[1] *Тура* — елга исеме.
[2] *Манси* — аз санлы Себер халкы.

— Гафу ит, — дип
Дәшмәк булам
Ерактагы, тайгадагы мансига.
Әмма халкым
Миңа андый
Вазифалар
Тапшырмаган —
Ашыкмый тор, тыел, күнел, ярсыма!

Иркен Төмән!
Монсу Төмән!
Юмарт Төмән!
Кызу Төмән!
Минем Төмән — Туган ягым капкасы!
Сиңа кайтсам,
Мин сагаям:
Сүзләр эзлим,
Сүзләр сайлыйм —
Килми йөрәк тотып ялгыз ятасым.

### Мин бүген хан

Елга читләре
Ката торган чак.
Чуртан сайлыкка
Ята торган чак.

Көймә борнына
Учак асабыз.
Төнгә ышкылып
Түбән агабыз.

Учак яктырта
Балык дөньясын...
Җәннәттер бу дип
Уйлап куясын.

Анда да чуртан,
Монда да чуртан...
И туган ягым,
Бүген мин — зур хан.

Теләсәм: чәнчим.
Теләсәм: җәллим.
Теләсәм: төртәм,
Уйнап үткәлим.

Чуртан күзләре
Җемелдәп куя.
Тәнем, йөрәгем
Чемердәп куя.

Һәм күрәм шунда
Бүрәнәдәйне!
Чәнечке сабы
Йолкый гәүдәмне...

...Тынам, суынам.
Берни котыртмый.
Йолдыз күплектән
Күгем чытырдый.

Канәгатьләнеп
Сүрелә учак.
Чынлык хыялны
Юмалаган чак.

Аяз, яңрау төн.
Көймәдә чуртан.
Бөтен Себергә
Мин — бердәнбер хан!

## Чалдон теле

Юк. Көлкеле, мескен түгел
Чалдон анамның теле.
Ул бит татар телебезнең
Иң серле, моңлы күле.

Ничек аны сай дип әйтим —
Төбенә җиткәнем юк.
Ничек аны тар дип әйтим —
Ярыннан үткәнем юк.

Кайтсам — аның бәбкәсе мин, —
Туп-туры чумам, йөзәм.
Табигатькә, борынгылыкка
Якынаюны сизәм.

Эчәм, эчәм — эчкән саен
Сусавым арта бара.
Күзләр, йөзем, күкрәкләрем
Монда күпчеп кабара.

Тыңлап телнең яңгырашын
Тәмләп елап аламын.
Фәрештәләр монда гына
Чайкыйлардыр тамагын.

...Ничек мескен булсын
Теле чалдон анамның.
Күл корыса Себеремдә,
Сүнәр теле татарның.

## Күңел елый

Тәүде, Тубыл, Тура, Иртеш ярларында
Учак ягып бераз яткыным бар.
Дулкыннардан, камышлардан, яфраклардан
Ишеттем мин бер үк ачы моң-зар.

Гарьлегемнән туфрак чәйнәп, йөрәк кысып,
Ярларында корттай бөгәрләндем.
Куе томан эчләреннән олы көчме,
Нидер көтә-көтә юләрләндем.

Газиз халкым язмышының шаһиты — ай
Ник елмайсын шунда юри генә.
Боекланган, моңсуланган буйсынып ул
Ачы хакыйкатьнең ирегенә.

Учагымның очкыннары югарыга
Талпына да менми — чыртлап сүнә.
Карый белсәң: күк йөзендә — акылсызлык!!!
Гөрли, ыжгыра ул — ничек кенә!

Моң-зарларны тыңлыйм да мин, күңел елый:
Ия тугелмен күк үз-үземә.
Дан җырларга гына кала Себер
Татарның мәэюс түземенә.

Тәүде, Тубыл, Тура, Иртеш ярларында
Учак ягып бераз ятканым бар.
Сүлпән булды, ахры, учакларым —
Өермәләр килеп капмадылар.

## Гаҗәп авыл


Бик матур бер авыл бар —
Менә шунда мин туган...
Алан саен — карлыган,
Агач саен кош кунган.
Кычыткannar, әремнәр —
Әйтерсең генераллар,
Нурга ничек балкырга
Өмер бирeп торалар.
Башаклары тул-тулы
Кырда үскән бодайның:
Төшсә, тузан туздыра,
Башын тишә тургайның.
Күлмәгеңне сал да сөз
Җан теләгән балыкны.
Урамнарда төннәрен
Кыр үрдәге бакылдый.
Тимәгәндә, этләре —
Бик сабыр, акыллылар:
Тынычлыгын авылның
Чиратлашып саклыйлар.
Малайлары да үзгә —
Күз тидереп куймa.
Кош баласын, егылса,
Кире мендереп куя.
Чык күренә үләндә,
Былбыл күкәе булып.
Ак болытлар карала,
Шомыртларга ышкылып.
Кәкре-бөкре агачка
Йөгереп менә кәҗәләр.
Мөгез ышкып каерга,
Сөзешергә дәшәләр.
Чукып киндер орлыгын,
Тавыклары исерә.

Бутап, сала күкәен
Күршеләре жиренә.
Яши әле бабайлар
Сәламләргә өйрәткән.
Сирәк очрый агайлар
Сүгенергә өйрәткән.
Аһ! Киченең, таңының
Күңелләрне айкавы!
Кылтырата җырларга,
Хәтта чукрак, сакауны!
Татар теле үзелми,
Шундый матур янгырый!
Читтән килмәвенә ул
Шик-шөбһәләр калдырмый.
Кире кайтып җылына
Киткәннәре — туңганда.
Илдә чыпчык үлми шул,
Мондый авыл булганда.
Карап тырыш халыкка,
Килеп тора эшлисе.
Тыңламасаң киңәшен,
Берчак терсәк тешлисе.

...Кичерең, масаюны
Белмим ничек тыярга:
Нинди гаҗәп авылда
Насыйп булды туарга!

## НИКОЛАЙ ШӘМСЕТДИНОВ

*(1949)*



*Николай Меркамал улы Шәмсетдинов Төмән шәһәрендә яши. Беренче шигырьләре матбугатта 1966 елда басыла. Ун елдан соң «Литературная Россия» атналык гәзитендә аның шигырьләре беренче мәртәбә бөтенрәсәй укучысына тәкъдим ителә.*

*Николай Шәмсетдинов М.Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый. 1980 елда Свердловск (хәзер Екатеринбург) китап нәшриятында беренче шигырь җыентыгы басылып чыга. Хәзер ул унбишләп китап авторы.*

*Николай рус телендә иҗат итә. Хыялы — татар теленә тәрҗемә ителгән шигырьләренең Казанда басылып чыгуын һәм иҗатының киңкүләм татар укучысына барып җитүен күрү.*

## Себер[1]

Бик җайсыз да, борынгы да бу як.
Урман саен авыл ята йоклап.
Күктә йолдыз — тәңкә сипкән сыман,
Ат ялары уйнап тора чыктан.

Менә Себер!
Тыңлап арба җырын,
Күпме үткәнем бар авыл юлын.
Нәкыш кәрнизле җиз ызбалар
Салынганнар балта белән юнып.

«Караңгы як» дип башлыйсы килә...
Озынборын баскан сазлык җирләр.
Ачыла миңа усак шауларында
Элек «тозак» булып яткан серләр.

Суза монда металл тасмаларын
Транстайга магистрале.
Көмеш тәңкәләрдәй уйнап тора
Мускулларда чык-тир бөртекләре.

Тормыш кайный монда, ташкын булып
Агыла корыч, битум һәм пыяла.
Алтын киңлекләрдә тирләп-пешеп
Башлана көн шулай өр-яңа.

Тынгы бирми сәяхәтләр җыры:
«Күп яшь койдың, нарат, җитәр, тукта!
Шәрә кабыргалы шпаллардай
Ят сузылып әнә шул сазлыкка!»

Һәм ул ята,
Боз челтәрен ватып;

[1] Рафис Корбан тәрҗемәләре.

Жил тузгытып, дулап, акырып
Һәм ыжгырып өскә килгән состав
Әйтерсең лә җуя акылын.

...Мөмкин матур төсләр белән манып,
Игътибарны читкә күчерергә.
Җете кызыл тапны урман итеп,
Зәңгәр белән күлне төшерергә...

Тик могҗиза булып бүген монда
Оча күпер, дөмбәсләнә субай.
Турбиналар суза труба җырын,
Шаккатырып кара якны шулай!

**Обь**

Кайтам салмак Обь ярына,
Кагылып үтәм суларына,
Искә алып бала чакны
Чумам татлы уйларыма.

Яшьлегем чагылмый суда.
Керәшәләр күкне телә.
Комдагы эздәй юыла
Калган хәтер, үч һәм үпкә.

Чумам хәтер төпкеленә...
Затоннарда хезмәт шавы.
Төнге суда ишетелә
Назлы йолдыз пышылдавы.

Җемелди чык яфракларда.
Ә мин атлыйм комлы ярдан,
Язгы ташу киңлегенә
Сокланып һәм калып хәйран.

Кая бакма — балыкчылар!
Ялкын бии учакларда.
Мәрсин йөзә суны ярып,
Чуртан уйный ул чакларда!

Йоклап ятар вакытмыни, —
Балыкчының урак өсте.
Кыштыр-кыштыр килеп тора
Чуерташтан аяк асты.

Кайтам салмак Обь ярына,
Кагылып үтәм суларына.
Искә алып бала чакны
Чумам татлы уйларыма.

Уята таңны ишкәкләр.
Рәхмәт язгы иртәң өчен,
Рәхмәт, Обем!
Рәхмәт, миңа
Көч, матурлык биргән өчен!

### Юл чәе

Йөгерә җигүле этләр,
Таралып, карга сеңеп!
Чаналар чатта салулый,
Кагырны[1] көртка күмеп.

Эштә этләр...
Тундра буйлап
Агыла шуган тавыш.
Сыпырып ала сыртларны
Котсыз тизлектә чабыш.

---

[1] *Кагыр* — җигүле этләрне идарә итүче.

Очлы чум янына җитеп
Туктап кала юлчылар.
Иртәнге чум юлчыларын
Ни-нәрсә белән сыйлар?

Көч-хәл белән ачыла тел
Җылыда.
Аяк янә
Тоя җирне.
Соры көлдә
Ялкынланып ут яна.

Кояш
Кагылып биткә, аякка
Назланып сырпалана.
Ә самовар җырлый —
Чумда
Чәйдән хуш ис тарала.

Рәхәт! —
йонлач кайры туннан.
Чәй эчү тәмен белеп,
Җылысы шифалы чәйнең
Тарала тәнгә сеңеп.
Уята күзәнәкләрне,
Йокыны куа күздән.
Эч, әйдә! —
Язылсын тәннәр,
Арганлык качсын бездән.

## Болан

Чәлпәрәмә килде күл көзгесе,
Очып кына кичте суны болан.
Чәчрәтеп, суын какты өстән,
Ярга менде аннан авыр сулап.

Чапты хайван, өркеп, өскә килгән
Үлем машинасы — вертолеттан.
Һәм дөньяга чиксез курку акты
Күзләренә төшкән кызыллыктан.

Ул ыргылды.
Ишетелде бары
Бугаз төбе белән гырылдавы.
Ә мин,
авырткачы уртны кысып,
Язып телдән,
Хәлсез тордым басып.

Өскә килгән авыр, үҗәт металл
Җимереп анны
Үсте, көчәйде.
Күзе тонган, шашкан хайван юлын
Бүлеп,
Чишмә агып төшә иде.

Тайпылды да читкә,
Гаип булды
Үзенә баккан мылтык күзеннән...
Кичке урман
аны
Кайгыртучан
ата кебек
Яшерде үзенә.

Янгырады шунда ату тавышы!
Агач башларында сил куптарып,
Юкка гына гөрселдәде өстә,
Өркү салып урманга,
Вертолет.

Урман алды улын —
Ул өлгерде!
Куйды дөнья
Җиңел сулыш алып.

Төн житәр дә
Вертолет югалыр.
Урман шунда тәмам тынып калыр,
Ә һавада бөтнек исе булыр,
Таралыр,
һич дары исе калмас.
Балалары өчен хәвефләнгән
Табигатьне генә йокы алмас.

**Кичке паром**

Хатыннар жырлый
Кичүдә.
Моңлы жырлар —
аларга
Шушы жырлар канат куйган
Илдә сугыш барганда.

Күнелнен түрендә
кайнап
Ургый көтү сагышы.
Әйтерсең киелми калган
Туй күлмәге җилфердәве —
Сукыр янгыр тавышы.

Гөрселди яшен — кайтаваз
Гүя ерак тупллардан.
Аналарның бар хәсрәте
Шушы җырда тупланган.

Сагыштан сукырайткан җыр
Ерагая...
Еракта
Ишетелә бары тонык
Елау булып колакта.

Юеш паром такталары,
Дулкыннар кага ярга.
Уфылдап-уфылдап куя
Бәрелеп субайларга.

...Җырдан саркыган сагышка
Чумып, мин торам ярда.
Аһ, ул җырлар,
Туган
мәңге
Онытылмас газапларда!

Хатыннар җырлый
Кайгыдан,
Карарга кыймый туры.
Яңгырый
Хәтер түреннән
Саркылып
Сөю җыры...

## ЗАҺИД АКБУЛӘКОВ

*(1939)*



*Заһид Акбуләков — тумышы белән Башкортстанның Караидел районы Иске Акбуләк авылыннан. 1956 елда урта мәктәп тәмамлагач, ул, Аскын авыл хуҗалыгы училищесында укып, механизатор һөнәрен ала. Үз теләге белән Казакъстанга чирәм җирләрне үзләштерергә китә. 1960 елда армия сафларына алынып, хәрби училищеда укыганнан соң, калган гомерен, отставкага чыкканчы, хәрби хезмәткә багышлый. Шигырьләр яза. Шигырьләре 1990 елда Төмәндә чыга башлаган «Яңарыш» гәзитендә басыла. Ул «Себер моңы» (1995) һәм «Тормыш бизәкләре» (2002) исемле ике китап авторы.*

*«Яңарыш» редакциясе каршында оештырылган әдәби берләшмә Заһид Акбуләковны Татарстан Язучылар берлегенә кабул итүне сорап мөрәҗәгать итте. Аның иҗаты берлекнең шигърият остаханәсендә тикшерелеп, ул Татарстан Язучылар берлегенә әгъзалыкка тәкъдим ителде.*

## Омтыламын

Гүзәллеккә омтыламын,
Саф булсын дип хисләрем.
Яшәүгә нурлар өстәсен
Кылган барлык эшләрем.

Мәрхәмәткә омтыламын —
Сердәш эзлим җаныма,
Якынаям бу яшәүнен
Чыганагы янына.

Изгелеккә омтыламын,
Кимесен дип тапларым.
Аңардан да өстен сыйфат
Гомердә дә тапмадым.

Яктылыкка омтыламын,
Барын үтә күрергә,
Изге нурлар агышында
Бәхетемне үрергә.

Биеклеккә омтыламын,
Яңа офык ачарга,
Илаhи гаҗәп яшәүне
Җаным белән кочарга.

## Әниләрнең яшь чагы

Атлы ургыч. Көлтә бәйләү.
Басуда җыр агыла.
Хатын-кызлар, көч, тир түгеп,
Эштә уттай кабына.

Индә капчык. Ара ерак.
Орлык ташый аналар.
Иңгә җирне салып, гүя
Баралар да, баралар.

Тишек чабаталар белән,
Себереп юл тузанын,
Тирән тоя йөрәк һаман
Әниләрнең узганын.

Сугыш афәте коточкыч,
Язмышларны бутады.
Берчак килеп, җиребездә
Кан коелу туктармы?

Тукыла тик михнәтләрдән
Әниләрнең яшь чагы.
...Ана сөю-көюендә
Дөрли тормыш учагы!

**Кошкайларым**

Күчмә кошкайларым кабат кайтты,
Канатларын җилпеп җанымда.
Карап сокланырга насыйп булды
Сихри язкаемда тагын да.

Бала кошчыкларның чыр-чулары
Тибрәлдерер күңел кылларын.
Бик тә үзгә кабул итә йөрәк
Кошларымның килү моңнарын.

Кошкайларым кайту шатлыгыннан
Якты сыман язгы һава да.
Киекләрнең җанны иркәләве —
Олы сихәт, изге дәва да.

Күчмә кошкайларым кабат кайтты,
Сафландырып җаным, халәтем.
Дан җырлармын сезгә, кошкайларым,
Булган кадәр газиз сәләтем!

## Тап төшермик

Затны нәрсә кеше итә?
Милләтенә табыну,
Якты яшәү өчен өндә,
Жаны белән кабыну!

Затны нәрсә кеше итә?
Телне, динне ярату —
Аларның куәте белән
Көн дә Иман яңарту!

Затны нәрсә өстен итә?
Акылының куәте,
Аны гел алга әйдәүче
Ата-баба нияте!

Жиребездә кем сон тагын
Акыл белән эш итә?
Акылы сайга тап булу
Хәтта жанны өшетә.

Затны нәрсә Кеше итә?
Сөю гадел-изгене,
Чыгырдан чыгармый торган
Газиз яшәү тезгене!

Кеше — Жирдәге яшәүнең
Дәрәжәсе, асылы —
Кирегә үзгәртмәс аны
Изге тормыш басымы!

Затны нәрсә өстен итә?
Омтылуы сафлыкка,
Бөеклеген хак дәлилләп,
Табынуы аклыкка!

Биек, матур, якты яшик,
Тап төшермик халыкка!

## Нәсыйхәт

Барам алга, як-ягыма
Күз салам;
Йортлар матур, юллар асфальт —
Үз калам!
Тормыш күркәм, яшәү рәхәт,
Тик шатлан!
Хуҗа бул, вакыт сыртына
Мен, атлан!
Җир, халык бәхете өчен
Гел яшә —
Гүзәл мәгънәле булырга
Ил дәшә!
Рухи байлыкта күрә бел
Бәхетне!
Тик карьерист үз итәдер
Тәхетне.
Эзләреңдә чәчәк атсын
Тик гөлләр,
Синең белән телгә килсен
Хет җилләр!
Акылга ия булуны
Исбатла —
Баклыкларга, сазлыкларга
Һич батма!
Матур яшә, бәйсез вакыт
Чамалы!
Исеңдә тот, һич онытма
Чаманы!



# ГӨЛНУР ХӘЙРУЛЛИНА

*(1937)*

*Гөлнур Әкрам кызы Хәйруллина Төмән өлкәсенең Эске авылында туган. Шунда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Тубыл педагогия училищесында белем алып, Түбән Тәүде районының Урманбаш авылы мәктәбендә 42 ел буе балаларга белем һәм тәрбия бирә. Бала чагыннан ук шигырьләр яза. Беренче шигырьләре, Тубылда укыганда, «Яшь ленинчы» гәзитендә басылып чыга.*

## Туган телем

Туган өем — әби әкиятләре,
Әниемнең бишек җырлары.
Тәрәзә төбендә — кына гөлләр,
Бакчабызда — кошлар сайравы.

Туган җирем — гади авыл җире,
Тирә-ягы кырлар, урманнар.
Борыла-борыла аккан елга,
Таңнарында төшкән томаннар.

Туган илем — бөек Себер иле,
Данлы Төмән — аның каласы.
Мин шул илнең бер бөртеге булам,
Татар халкының газиз баласы.

Туган телем — мәшһүр Тукай теле,
Горурланып яшим — хакым бар.
Матур телле, моңлы, назлы телле,
Ислам динле татар халкым бар.

## Авыз пешкәч

Бер сазлыкка кереп баттым:
Янәсе, тизрәк житәм.
Сусыз, уйсу жир күрсәм дә
Хәзер әйләнеп үтәм.

Һаулап чыкты каршыма ул,
Куркып калдым зур эттән.
Кечкенә көчек күрсәм дә
Хәзер әйләнеп үтәм.

Каршы килә үгез дулап,
Кайчан сөзә дип көтәм.
Яңа туган бозауны да
Хәзер әйләнеп үтәм.

«Авызы пешкән өреп кабар», —
Дип әйткән зирәк халкым.
Салкын чишмә суын да мин
Нигәдер өреп каптым.

**Себерем — алтын бишек**

Кавказларга мин бармадым,
Кырымнарда мин булмадым,
Себердәге матурлыкны
Беркайда да табалмадым.
Күнелем кителеп боекканда,
Шифа алам урманыннан.
Башым терәп усагына
Котылам баш авыруыннан.
Зиһеннәрем таркалганда,
Баш әйләнеп борчылганда;
Ачы миләшләрен кабып,
Сихәтләнәм дәва табып.
Аяк-куллар сызлаганда
Файда бирә сазлыгы да.
Саф һавасы, чишмә суы
Бәлзәм булып ята җанга.
Җиләкләрен, гөмбәләрен
Җыеп алу мөмкин түгел.
Күз яменнән, күз монынннан
Тынычланып кала күнел.
Ләззәтләнәм алтын күзнен
Төсле мизгелләре белән.
Барган күйгә ят та йокла —
Аяк асты чуар келәм.
Туган ягым — алтын бишек,
Сихерләден мине күптән,
Җибәрмәден син үзеннән,
Күпме еллар инде үткән.

## Хәерле иртә

Хәерле иртә телим таңнарда,
Авылдашлар, күрше-куләннәр!
Хәерле иртә, бакчам, гөлләрем,
Хәерле иртә, яшел үләннәр.

Хәерле иртә, сары сандугач,
Үзәкләрне өзеп сайрыйсың.
Талдан талга күченә-күчenә
Шулай сайрап оя сайлыймсың?

Хәерле иртә сезгә, укучылар,
Белем сараена барышмы?
Тел ачкычы бирсен, тырышыгыз,
Берегез дә артта калышмый.

Хәерле иртә, печән чабучы,
Утлап йөри шунда алаша.
Тургай сайрый, күбәләкләр оча,
Тирә-юньдә хәйран тамаша!

Хәерле иртә, туган төбәгем,
Муллык-байлык телим җиремә.
Аяз күкләр, имин тормыш телим
Һәм тынычлык телим илемә.

## Берсе минеке

Йомшак куллы әниләрнең берсе минеке,
Яуда калган әтиләрнең берсе минеке,
Яшеренгән сукмакларның берсе минеке,
Яуланмаган тау-үрләрнең берсе минеке,

Исеме юк йолдызларның берсе минеке,
Язылмаган шигырьләрнең берсе минеке.
...Юк, юк — дан, шөһрәт теләми күңелем минем,
Үземне генә табып китим әле, димен.

## Чәчләр чәчкә бәйләнгән

Бакчадагы бер гөл булсам,
Син — гөлдәге күбәләк.
Синең белән бергә чакта
Бәхетләрем түгәрәк.

Дәрьядагы су булалсам,
Син — аның текә яры.
Меннәр арасыннан сайлап
Сөйдем бит сине, ярым.

Су буенда бер тал булсам,
Син — аның сандугачы.
Сандугачлардай гөрләшеп
Гомер итеп булсачы.

Зәңгәр күктә ай булалсам,
Син — шунда якты йолдыз.
Мәхәббәтне уртак иткән
Бер егет һәм чибәр кыз.

Мин — агач, син — ябалдашым,
Мин — зәңгәр күк, син — кояшым.
Чәчләр чәчкә бәйләнгән,
Икәү бергә әйләнгән.

## Ник булмадым

Җилләр булып ник тумадым,
Таңнарда исәр идем.
Кара бөдрә чәчләреңне
Иркәләп үтәр идем.

Дулкын булып ник тумадым
Син коенган суларда?
Башым куеп күкрәгеңә,
Йөрәк тибешең тыңларга.

Йолдыз булып туган булсам,
Атылыр идем җиргә.
Сиңа төшкән авырлыкны
Күтәрер идек бергә.

Ник булмадым мин сандугач,
Алларында сайрарга,
Бик боеккан чакларында,
Күңеләңне табарга?

Карлар киткәч, чирәм булып
Чыгар идем яшәреп.
Егылсаң, аяк астыңа
Ятар идем түшәлеп.



## ГАЛИЯ АБАЙДУЛЛИНА

*(1940)*

*Галия Төхфәтулла кызы Абайдуллина 1940 елда Тубыл районының Саускан авылында туа. Бәргән башлангыч мәктәбен, Сатылган җидееллык мәктәбен һәм Тубылда 15 нче номерлы урта мәктәпне тәмамлый. Педагогия училищесын тәмамлап, Тубыл районының иң төньягындагы сазлыклар, күлләр кочагында урнашкан Лаемтамак һәм Вәчир авыллары мәктәпләрендә 35 ел балаларга белем һәм тәрбия бирә. Гомере буе шигырьләр яза. Шигырьләрен 1990 елда Төмәндә «Яңарыш» гәзите басыла башлагач кына матбугатта чыгару мөмкинлеге туа. Галия Абайдуллина «Гафу итәрсезме, чәчәкләр» дигән җыентык авторы.*

## Саргайтмагыз газиз аналарны!

Бу хатны мин язамын
Бәгъре таштай катканга.
Ата-анасын онытып
Дөнья куып чапканга.

И балалар, сезне бу дөньяга
Теләп, көтеп, сөеп бар иттек.
Үсеп, очып ерак киттегез,
Безнең чәчне көмеш кар итеп.

Әни өчен бала бала булып
Кала икән алтмыш яшькәчә.
Сагынасың, борчыласың һаман,
Яшәп булмый икән башкача.

Ничек үстергәнне ничә тапкыр
Шигырь итеп язды шагыйрьләр.
Ерактагы йөрәк парәң өчен
Телгәләнә икән бәгырьләр.

Саргайтмагыз газиз аналарны,
Кайталсагыз, ешрак кайтыгыз.
Кайталмаган чаклар булганда,
Кош теледәй хатлар языгыз.

Шунсына да риза ана-карчык,
Исән-имин икән, ди, балам.
Әбисеннән дога-теләк алып
Үсеп житәр әле үз балаң...

Шунда инде күз алдына килер
Әни-бәгърең, ләкин соң булыр.
Сагынудан, йөрәк әрнүеннән
Күзләреңә кайнар яшь тулыр.

Интекмәсен газиз аналар,
Ташламагыз картлык көнендә!
Сездән булган изге хөрмәт белән
Шатлык артсын картлык көгендә!

## Яратам мәктәбемне

Яратам мәктәбемне,
Укытучы апамны.
Ярты көн буена апам
Алмаштыра анамны.

Уку-язуга өйрәтә
Һәм тәртипле булырга.
Ярамый икән шапшаклык
Һәм сонга да калырга.

Апам гел елмаеп тора,
Әгәр яхшы укысак.
Өйрәткәнен, сөйләгәнен
Һаман тынлап утырсак.

Тәнәфес вакытларында
«Мәче-тычкан» уйныйбыз.
Ял итеп тә өлгерәбез —
Мәктәптән һич туймыйбыз.

Тырышып укыйм, шуңа мин
Гел «4»ле, «5»ле алам.
Рәхмәт сиңа, мәктәбем
Һәм укытучы апам!

## Мәхәббәтнең яше булмый икән

Гомер үтәр, яңа язлар килер,
Тик үткән мәхәббәт терелмәс.
Акыл башлык булгач, шук йөрәгем
Сөю хисе эзләп тилмермәс.

Замананың төрле чагы булды:
Сугыш... ачлык... үксез ятимлек.
Тик шулай да ярсу йөрәкләрдә
Тиле яшьлек итте хакимлек.

Акыл белән түгел, йөрәк белән
Өзелеп сөйгән чаклар булдылар.
Вакытсыз йөгән кигән йөрәкләр
Изге хисләр белән тулдылар.

Мәхәббәтнең яше булмый икән,
Һәрнәрсәнең яше булса да.
Мәхәббәт — ул изге бер хис икән,
Алты, җиде дистә тулса да.

Үкенерсез, ләкин бик соң булыр,
Терсәк якын — җитмәс тешләргә.
Хыянәт итмәгез саф хисләргә,
Соң белмәссез хиссез нишләргә.

Онытылмас икән гомер буе
Өзелеп сөйгән беренче ярлар.
Васыять сезгә: ялгышмассыз һич тә
Кавышсагыз, беренче парлар.

## Җәлил шигырьләре

Җәлил шигырьләрен укыгач та,
Шигъри моңнар туа йөрәктә.
Сихри сүзләр табам иҗатыннан,
Киңәшергә әгәр кирәксә.

Үлмәс шигырьләре моң, җыр булып
Урнашалар кереп йөрәккә.
«Вәхшәт» кебек көчле шигырьләре
Чакыралар изге көрәшкә.

Мең газаплар белән сыкрап чыккан
Богау чаңы килә җырыннан.
Иҗат җимешләре түгелеп калган,
Табылырмы Алман кырыннан?

«Бөркет» булып ирек даулады ул,
Яшьнәп-күкрәп Алман иленнән.
Онытылмаслык булып, бизәкләнеп
Даны кайтты көрәш юлыннан.

Һәрбер сүзе үткен ядрә булып
Дошман йөрәгенә ут атты.
Төрмәләрдән, подваллардан чыгып,
Изге көрәшкә! — дип яуятты.

Егерменче гасыр азагында
Җәлилчеләр бармы сафларда?
Яңа афәт, кайгы-хәсрәттән
Әзер булыйк җирне сакларга.

## Озак яшә, «Янарыш»!

«Бисмилләһи» дип башлыймын,
Сүзем «Янарыш» өчен.
Укыган саен шатланып,
Тоям мин аның көчен.

Ала белсәң — акыл бирә,
Өйрәтә көнкүрешкә.
Түземле, сабыр булырга —
Аяк бассаң тормышка.

«Янарыш»ның битләрендә
Тарихыбыз чагыла.
Көн күрергә өйрәткәндә,
Үткәннәргә кагыла.

Ачыктан-ачык сөйлиләр
«Янарыш» битләрендә:
Яшәмәсен татар халкы
Тормышның читләрендә.

Онытмый «Янарыш» туган
Якташларның язмышын.
Адашканга булыша ул
Төзәтергә ялгышын.

Ил шатлыгын, дөнья хәлен,
Яңалыклар беләбез.
Сүрә аятьләрен укып,
Иманнарга киләбез.

«Янарыш» — фикер агышы,
Анда — халкым язмышы.
Явызлыкны тәнкыйть итә,
Күрә ямьсез-ялгышны.

Әкият, табышмак, мәзәк,
Кроссворд, көлдергечләр.
Уңмаганны, тәртипсезне,
Ялкауны бөлдергечләр.

«Сөю чишмәсе»ндә яшьләр
Рәхәтләнеп коена.
Аннары туйлар башлана,
«Әпипә»ләр көенә.

Туган көн, бәйрәмнәр белән
Берсен берсе котлыйлар.
Картны, яшьме йә баламы,
Ансын тиргәп тормыйлар.

Балалар да шатланалар
Матур шигырьләренә;
Ижади уңышлар теләп,
Яңа шагыйрьләренә.

Программалар, белдерүләр
Кайчакта ярап куя.
Үзенә тигән тәнкыйтьне
Түрәләр... карап куя.

Кайда? Кайчан? Ни булган?ын
«Яңарыш»тан беләбез.
Мең дә бер сораулар бирен,
Киңәшергә киләбез.

«Яңарыш», син озак яшә!
Гомерең озын булсын.
Бәхет, шатлык, иминлекләр
Белән битләрең тулсын.

«Яңарыш» хезмәткәрләре,
Уңышлар телим сезгә.

Шатланып каршы алырбыз,
Килсәгез әгәр безгә.

Милләттәшләр, татар халкым,
Тату, дус, туган булыйк.
Бәхәскә, талашуларга,
Ачуга юллар куймыйк.

«Янарыш», озак яшә!
Йөрәкләр шулай дәшә.

## Туган тел турында мөнәҗәтләр

Аллаһу бар, Аллаһу бер,
Ышаныгыз шушына.
Фани дөньяга бар булдык
Аллаһу кушуына.

Тәңре безне риза итеп
Бүләк иткән Туган тел.
Иман китерер өчен дә
Кирәк безгә Туган тел.

Ана телен — Туган телен
Пәйгамбәрләр яраткан.
Динне саклап калыр өчен
Изге гыйлем тараткан.

И Туган тел, синең белән
Дөнья көтү рәхәттер.
Милләтне яклаучы иттең,
Шуның өчен рәхмәттер.

Иманыбыз камил булыр,
Туган телне сакласак,

Аллаһ Тәгалә риза булыр,
Без милләтне якласак.

Теле юкның — көне юктыр,
Саклагыз Туган телне!
Аллам биргән, атам-анам
Һәм Тукай биргән телне!

### Тел

> Дөньяда күп нәрсә белдем
> син туган тел аркылы.
>
> *Г.Тукай*

Аллам биргән тел,
Анам биргән тел.
Яхшылык теләп
Дуслаштырган тел.

Уяткан да тел,
Юаткан да тел.
Дусларны очратып,
Табыштырган тел.

Тауга мендерә,
Суга иңдерә;
Ә кайчакларда
Жанны көйдерә.

Сөйдергән дә тел,
Көйдергән дә тел.
Утларга салып,
Тартып алган тел.

Яраштыра ул,
Кавыштыра ул.
Уйга-сагышка
Сабыштыра ул.

Моңландыра тел,
Шомландыра тел.
Канатлар биреп
Талпындыра тел.

Яхшының теле
Бирә сабырлык.
Тел ярдәмендә
Килә батырлык.

Явызның теле
Канга тоз сала.
Телнең ярасы
Мәңгегә кала.

Гайбәтче теле
Очлы без кебек,
Гайбәтче сүзе
Салкын боз кебек.

Куллана белсәң,
Тел — яхшы корал.
Тик нәтиҗәсе
Җаваплык сорар.

Ана телеңне
Белергә кирәк.
Дөнья көткәндә,
Тормыш корганда,
Ул — яхшы терәк.

Үтергән дә тел,
Терелткән дә тел.
Тел бер могҗиза,
Шуны яхшы бел.

## Кемгә кирәк бу сугыш?

Тарих һаман кабатлана:
Чечня халкын кол итү;
Кансыз чаралар кулланып,
Бәйсезлеген юк итү.

Ярты гасыр көрәштеләр
Батыр Чечня уллары.
Яшькә, канга буялдылар
Вәхшиләрнең куллары.

Чеченнәрнең горур улы
Шамил күпме көрәште.
Рус явын җиңә алмыйча,
Ирексездән биреште.

Авыл, шәһәрләр яналар,
Җирле халык куыла.
Ирек даулап, чечен халкы
Мылтык алды кулына.

Җир белән тигезләделәр
Ташлы-таулы җирләрен.
Яндыралар, юк итәләр
Бакча, иген кырларын.

Ирекккә омтылган халык
«Бандит» ярлыгын алды,
Күп гаиләләр бу афәттән
Йортсыз һәм җирсез калды.

Үтерү, кыру, җимерү
Вәхшилеккә кирә бит.
Ахыры ни белән бетәр?
Халык сорау бирә бит.

Кемнәргә кирәк бу сугыш?
Белдерегез ачыктан.
Балалар, картлар, авырулар
Тилмермәсен ачлыктан.

Сталиннар килә тора
Геноцидны башларга.
Әфәнделәр, вакыттыр бит
Кан коешны ташларга!

### Халкыбызның күркәм йолалары

Татар булуыңа горурлансаң,
Гореф-гадәтләрен өйрән син.
Ә балалар күркәм йолаларны
Әби-бабасыннан өйрәнсен.

Гает бәйрәмнәре, уразалар,
Сабантуйлар, татар өмәсе —
Көч бирә һәм шатлык өсти безгә
Бәхетләр китерә һәммәсе.

Күркәм йолалары халкыбызның:
Бәби туйлар, исем бирүләр...
Саклап калыйк гореф-гадәтләрне,
Гаеп булмас динне белүләр.

Намаз уку хәзер гөнаһ түгел,
Сәдака бир, булмас ялгышлык;
Корбан чалып дус-туганны җыйсаң,
Савап булыр, итсәң яхшылык.

Дөнья малын куып, гайбәт сатып
Йөреми ул әдәпле халык.
Әче каралыкны, явызлыкны
Җиңеп чыгар сабырлык, хаклык.

Тәүфыйк, инсаф — төп сыйфатлар безнең,
Без намуслы, шәфкатьле, эшчән.
Мирас итеп саклап калыйк шуны
Һәм бервакыт чыкмасын истән.

**Хуш килдең, Яңа ел!**

Сагындык һәм көттек
Кыш бабайны без.
Кулга-кул тотышып
Янында биибез.

Котлап Яңа елны
Кунаклар килгән;
Тылсымлы битлекләр,
Костюмнар кигән.

Уртага зур чыршы
Бизәп куйганнар.
Бииләр «аюлар,
Төлке, куяннар».

Кар кызы назланмый,
Шаяра, көлә;
Чыршыны әйләнә
Ул биеп кенә.

Хуш килдең, Яңа ел!
Иминлек китер.
Иске ел шатланмый,
Шаярмый никтер.

Гаебе бар сыман
Поскан почмакка.
Синдә дә шатлыклар
Булды кайчакта.

Ике меңенче ел,
Кил хәерлегә.
Саулык, бәхет, шатлык
Китер һәркемгә.

Кыш бабай, Ак бабай,
Үт түребездән!
Сораганнарга
Сәлам илт бездән.

**Хуш киләсең, нурлы яз**

Иртә торсаң, саф һава
Кытыклый борыннарны,
Сөендерә күңелне,
Уйната буыннарны.

Бик ашыгып килә яз
Көмеш тамчысы белән.
Кар-бозларны эретә
Кояш камчысы белән.

Буранлы салкын көннәр
Котып якка китәләр.
Дусларыбыз — кошкайлар
Шатланышып киләләр.

Җәнлекләр өннәрендә
Сөенеп уяналар.
Тереклек дөньясында
Һәммәсе куаналар.

Нәүрүз — язда яңа көн,
Табигать тә янара.
Ачу-нәфрәт онтыла,
Бала-чага шаяра.

Хуш киләсең, нурлы яз!
Төкле аягың белән,
Бәхетле һәм мул булган
Уңыш таягың белән.

Дөнья шатлыкка чумсын,
Аналар тыныч булсын.
Күктә кояш балкысын,
Җирдә тынычлык булсын.

### Күчем хан

Кәрван — юлында Күчемнең
Җилләр булган юлдашы,
Аты булган турылыклы,
Фәрештәләр — сердәше.

Күчем ханның куәтенә
Күпләр хәйран калганнар.
Батыр даны дошманнарны
Зур куркуга салганнар.

Даны Себер киңлекләрен
Аркылыга һәм буйга
Айкап йөргән динен яклап.
Урыслар калган уйга...

Күчем хан —
ул чын мөселман,
Сәүдә юлында йөргән.
Затлы ефәкләр алырга
Матур кызлар йөгергән.

Исемең тарих битләрен
Мәңгелеккә бизәде.
Себер киңлеген яктыртып,
Даннан һәйкәл төзеде.

## Саклап калыйк туган телебезне

И туган тел, и матур тел,
әткәм-әнкәмнең теле!

*Г.Тукай*

Һәр гаиләне шатландыра
Баланың туган көне.
Баланың, анадан тугач,
Буладыр Туган теле.

Бишек жырын Туган телдә
Көйләп үстерсәң бала,
Картлыгында шат яшәрсең,
Булмас башыңа бәла.

Милләтен хөрмәт иткәннәр
Өйрәтер Туган телен,
Дөнья белән таныштырыр,
Онытмас Тукай телен.

Туган телем, Булат теле,
Җәүһәрлесең, затлысың.
Чынлап та горурланырлык
Төрки-татар атлысың.

Үз телеңне белмәү — хурлык,
Өйрәнмәү — зур ялгышлык.
Ыру телен белмәгәнне
Алда көтә ялгызлык.

Бөек шәхесләребездәй
Калыйк без дә әдәпле.
Саклап калыйк телебезне,
Йола, гореф-гадәтне.

## Татарым

Татар һаман яшәп калган,
Киссәләр-ассалар да.
Һаман үсәргә тырыша,
Башыннан бассалар да.
Килмешәккә кул биргәнме?
Беткән Себер ханлыгы.
Бүген ятлар кагыйдәсе
Хокуклымы? Хаклымы?
Телен сата, имеш, татар,
Төштә күреп уяндым.
— Йоклап ятар чак түгел! — дип,
Шигырь килеп уятты.
Булат якташ күп йөреде,
Яктыга юллар таптап.
Якуб абый китеп барды,
Татарны миңа ташлап.
Саклагыз, дип, татарымны,
Әгәр мин дә язмасам,
Дөреслекне күрегез, дип,
Күзләрен дә ачмасам,
Изге жаның, Якуб абый,
Риза булмыйча ятар.
Борчылмасын Булат жаны:
Шигырьсез калмас татар.
Шигырьләрем — бар байлыгым —
Юлыма куеп барам.
Милләтнең хәсрәт-михнәтен
Йөрәккә жыеп барам.
Себер жиренә ханнарның
Түгелгәннәр каннары.
Саталар дип татарымны
Хурланмасын жаннары.
Жирле Себер татарының
Озын юлы — хезмәтле.

Телен, динен саклый алса,
Калыр иде хөрмәтле.
Татар да яшәп ятсын дип,
Акча бирелә, имеш,
Кесәләрдә адаша, ди,
Дөресме имеш-мимеш?
Уйда — ил кайгысы булсын,
Түгел байлык кайгысы.
Бүген милләтне якларга
Лаекмы сез? Кайсыгыз?
Татарны танавы белән
Җиргә төртмәсен өчен,
Хокукны саклап калырга
Аямый бирик көчне!

### Хәерле иртә

Хәерле иртә!
Хәерле иртә, әнием!
Миңа җан биргән кешем.
Табигать! Рәхмәт, хәерле
Нурыңа төргән өчен.

Күк тыныч булсын, сайрыйсыз,
Хәерле иртә, кошлар;
Моңлы җырыгыз күңелнең
Кылларын чиртә, дуслар.

Хәерле иртәләр телик,
Тәннәр, җаннар төзәлсен;
Чәчәкләр елмаюыннан
Яшәүгә дәрт өстәлсен.

Иртәләр хәерле булсын
Нарасыйлар хакына.
Хәерле иртәләр телим
Илемә һәм халкыма.

## Дусларым

Шөкер итәм, якын дусларым бар,
Адашканда юл күрсәтергә.
Җиңел йөкне — үзем, авырларын
Булышалар дуслар күтәрергә.

Үрләр яулап очкан чакларымда
Дуслар миңа канат булдылар.
Сорау өермәсендә батырмый,
Өметемә илтеп куйдылар.

Хатага абынып егылганда,
Кайгы яшьләремне сөрттеләр.
Ташкын хисләремне егылтмыйча,
Хыял атларында йөрттеләр.

Дошман күзе булса икәү, дүртәү...
Дусларымның — сигез, уналты...
Кара төннәремдә шәм яктылар,
Сүнмәс йолдызлардан ут алып.

Җанны сатмый, йөзне буямаган
Дуслар белән яшәү күңелле.
Бәйрәм ашы, диләр, кара-каршы,
Кайчак онытыла түгелме?..

## Әнием — кояшым

Яратуымның олысы
Газиз анама,
Фәкать кояш нурын гына
Тиңлим аңарга.

Җирдә иң зур бәхет булып
Күренәм аңа.
Кояшка үрелгән кебек
Үреләм аңа.

Кояшыма рәхмәт әйтәм
Мин кабат-кабат,
Чөнки яшәү көчен бирә,
Үстерә канат.

Кеше булып үссен диеп,
Нурлар коясың.
Бик күп рәхмәт яусын сиңа,
Әнием-кояшым.

Иң кирәк кешем, тормышың
Шатлыкка тулсын,
Кояшныкы кебек озын
Гомерең булсын.

Тынычлыгыңны саклармын,
Борчылма, анам.
Күзләреңдә кояш нуры
Балкысын һаман.

## «Яңарыш»ны яратам

«Яңарыш»ны яратам:
Уй-фикерне яңарта.
Милләт артта калмасын дип,
Яңалыклар тарата.
Бүген әйтәсе сүзем:
Үсмер яшендә үзең,
Бабайлар акылы синдә,
Бик күпне күрә күзең,
Яңарышның күгендә
Күп йолдызлар күренә,
Яктыларын эләп куяр
Иҗатының түренә.
Бәхетең саклап торсын,
Уңышлар яклап торсын.
Телләшергә исәп тоткан
Дошманың йоклап йөрсен.
Гомере озын булсын,
«Яңарыш» дустың булсын.
Биргән үгет-нәсихәттән
Күңелгә иман тулсын.
Кызларыңа, улларыңа
Гел бирәсең кулларың.
Уңышлардан уңышларга
Илтсен сине юлларың.

## Сәләт кисәге

Кыска гомерле Тукайның,
Әллә инде... Такташның,
Өзелеп калган сәләтеннән
Әллә Булат якташның.

Әллә кемнең сәләтеннән
Адашып йөргән бер кисәк.
Алып куеныма тыктым
Һәм җылыттым бик озак.

Сәләт кисәге тирәлде,
Куенымнан башын сузды;
Соң булса да уң булсын дип,
Елмаеп күзен кысты.

Сәләт кисәге белән без,
Җитәкләшеп куллардан,
Киттек икәү сикәлтәле
Һәм бормалы юллардан.

Шатланабыз уңышларга,
Кайчакта пошынабыз.
Ялгыш язмыш екмасын дип,
Ялына тотынабыз.

Кырлайга барып кайтабыз,
Сыркыдыда булабыз,
Сопрага да барыр идек...
Анда ямьсез Булатсыз.

Бөекләр! Юк сезнең белән
Тиңләшергә исәбем.
Бик рәхмәт, калдырган өчен
Әзрәк сәләт кисәген.

## Себерем

Себерем, сокланам
Синдәге төсләргә.
Үлчәүләр житмәстәй
Бай иттең хисләргә.
Табигать үз миңа
Көзен дә язын да.
Байлыкка төренгән
Җәең дә, кышың да.
Мәһабәт урманнар
Сазлыклар үтмәстәй.
Себерем киңлеге
Күз-күрем житмәстәй.
Халкыма багышлыйм
Ярату назын да.
Күп итеп саныймын
Бәхетнең азын да.
Хисләрем, Себерем,
Тугрылар үзеңә
Хыянәт итмәмен,
Ышан син сүземә.

## СӘГЫЙТ СӘГЫЙТОВ

*(1947)*



*Сәгыйть Динмөхәммәт улы Сәгыйтов 1947 елда Төмән районының Ямбай авылында туган. Ишле гаиләдә тәрбияләнеп үскән Сәгыйть урта белемне Ямбай мәктәбендә ала. Байтак еллар Төмән өлкәсенең төньягында геодезист булып нефть эзләү белән шөгыльләнә. Буш вакытында шигырьләр язу белән мавыга. Төмән өлкә нәшриятларында басылып чыккан «Халык хәле» (1998) һәм «Сезгә әйтәм» (2000) исемле шигырь җыентыклары авторы.*

## Авылымны сагынам

Туган авылым, туган җирләрем
Матур җырдай һәрчак уемда.
Анда минем алтын сабый чагым
Гөрләп үтте шаулы уенда.

Анда бар да матур, җанга якын,
Тәмле кебек күлнең сулары.
Мәңге китмәс булып кайтам тагын
Сезгә, ямьле Ямбай кырлары.

Күл буенда бөдрә яшел таллар,
Сокланып та карап туймыйсың.
Китмәсә дә яшьләй сөйгән ярлар,
Туган җирем, үзенә тартасың.

## Авылга кайту

Һәркемгә дә ямьле туган ягы,
Онытылмый үскән авылым.
Мин кайтырмын, әни, синең янга,
Булсын гына әле саулыгың.

Мин кайтырмын сезон эшләр беткәч,
Зур рюкзакны тотып кулыма.
Бик борчылып сәдакалар салдың,
Бәхет теләп кайту юлыма.

Әллә ярдәм итте догаларың,
Баштан үтте нинди хәтәрләр!
Суда баттым, адашып та йөрдем,
Ишетмәдем начар хәбәрләр.

Кайтып килəм йөгерердәй булып,
Мәчет манарасы күренә,
Моңлы татар көе ишетелә,
Бер ямь өстәп авыл түренә.

Урам буйлап киләм сәлам бирен,
Татар, немец — барсы якыннар.
Капка ачып каршы әни чыккан,
Күзләрендә нурлар, ялкыннар.

### Онытмагыз әниләрне...

Елатмагыз бер дә әниләрне,
Уйламастан авыр сүз әйтеп.
Көтә әни һәрчак, көтә безне,
Тәрәзәгә карап интеге.

Тол калды ул жиде бала тотып,
Бетмәс кайгы һәрбер көендә.
Еламасын әни сагыш йотып,
Үзе ялгыз калып өендә.

Көтми әни бездән зур бүләкләр,
Сорамый да ансын-монысын.
Һәр намазда укый ул теләкләр,
Китерегез йөрәк жылысын.

### Мин яратам

Мин яратам әгәр язлар житсә,
Ярсып аккан ташкын суларын.
Мин бәхетле гомер әйбәт үтсә,
Сезнең белән, якын дусларым.

Мин яратам җәйнең аяз көнен,
Печән чапкан болын-кырларын,
Мин яратам туган татар көен,
Сагыш моңы тулган жырларын.

Мин яратам сөйгән ярым кайтса,
Сәфәр йөреп ерак иләрдән.
Үлеп сөям туган Себеремне,
Матур күреп бүтән жирләрдән.



## ФӘХРИҖАМАЛ ҮТӘШЕВА

*(1948)*

*Фәхриҗамал Габбас кызы Үтәшева Тубыл районының Ләчек авылында туып үсә. Тубыл шәһәренең 15 нче урта мәктәбен тәмамлап, Төмән авыл хуҗалыгы институтында югары белем ала. Вагай районының Птицы авылында «Фрунзенский» хуҗалыгында хисапчы һәм агроном булып эшли. Бер үк вакытта кулына каләм алып үзен борчыган проблемаларны күтәргән тирән эчтәлекле публицистик мәкаләләр яза, шигырьләр иҗат итә.*

## Җәйге иртә

Алыштыра ал шәфәкъны
Иртәнге нурлар чыны.
Янгырый ярып тынлыкны
Кәккүкнең беттәс моны.
Әкрен генә ата ал тан,
Исертеп яме белән,
Хәйран калып кошлар тора
Тукталып сайравыннан.
Керфекләрен күтәрә дә
Елмаялар чәчкәләр.
Җанга ләззәт, рәхәт биреп
Тарала хушбуй исләр.
Җилфердәтеп яфракларын
Агачлар да җанлана.
Дәрт биреп җирдә яшәүгә,
Яңа тормыш башлана.
Уяна барча тереклек,
Тик яшәргә омтылып.
Туклык жыя үсемлекләр
Нурларны комсыз йотып.
Иркәләнә назлы җирем
Кояшның кочагында.
Туа шулчак матур җырлар
Йөрәгем учагында.

## Авыл өе

Яратам мин авыл өен
Кышкы салкын кичләрдә.
Гөрли-гөрли каен утын
Янган чакта мичләрдә.
Яңарталар туган телне
Киләчәк һәм борынгы —
Әбиләрнең орчык җебе
Ялгый шулай буынны.
Якты бөрки тәрәзәсе,
Җылытып кара төнне.
Өмет белән авыл өе
Каршылый яңа көнне.

## Синең сөю

Синең сөю —
Талмас канат бирде,
Яшел киңлекләрдән
Зәңгәр күккә алып менде.

Синең сөю —
Сулмас яшьлек бирде,
Саф гөлчәчәкләрдән
Калышмый яшисе килде.

Синең сөю —
Чиксез бәхет бирде,
Гамьсез көнелләрдән
Гүя чәчкәләр сибелде.

## Кайда сез?

Кайда сез, кайда сез, кайда сез,
Җаннарга дәрт биргән якыннар?
Сезсез бит яшәве күңелсез,
Йөрәкне өтәләр ялкыннар.

Ялкынны сүндерер наз булып
Кайтыгыз, якыннар, кайтыгыз.
Яралы йөрәкне юатып,
Төшләрдә булса да кайтыгыз.

Нигә соң бозларын эретми
Бәгырьне көйрәткән ялкыннар?
Нигә соң аларны сүндерми
Күңелдән ташыган яңгырлар?

Ялкынны сүндерер наз булып
Кайтыгыз, якыннар, кайтыгыз.
Йөрәкне моңнарга чорнатып,
Җыр белән булса да кайтыгыз.



# КЛАРА КУЧКОВСКАЯ

*(1950)*

*Төмән өлкәсенең Ялутор шәһәрендә туып, Ревда дигән авылда үсә. 1967 елда Аслана мәктәбен тәмамлый. Бала чактан Айнинур әбисенең әкиятләрен, җырларын тыңлап үскән кыз үзе дә шигырьләр яза. Төмәндә «Яңарыш» гәзите чыга башлагач, аның беренче шигырьләре шунда басыла.*

## Шигырьләрем — бүләгем

Шигырьләрем юлдаш булсын
Ялгыз йөрегәннәргә.
Шигырьләрем җыр булсыннар
Җырлыйсы килгәннәргә.

Шигыремне бүләк итәм
Бәхетен югалтканга,
Күңеленә тынгы килсен
Шигырем юатканга.

Шигырьләрем маяк булсын
Юлыннан адашканга.
Алларында өмет булсын
Кайгысыннан шашканга.

Шигырь түгел, йөрәк җылым
Учлап-учлап таратам.
Шигырьләрем шифа булса,
Килер эзләп яңадан.

## Яратам мин

Яратам мин, ах, яратам
Сиксән яшьтә булсам да.
Таягыма эленеп,
Кых, кых, диеп, торсам да.

Яратам мин яшь кызларның
Уттай кара күзләрен.
Ах-ах итеп карап калам
Басып үткән эзләрен.

Яратам, яратам, яратам, дип,
Ирләр гомере үтә, ди.
Картайгач та кыш-кыш түгел,
Кыз-кыз, диеп әйтә, ди.

## Белми торсын

— Әби, мине кайдан алганнар?
— Әй, улым, кәбестәдән.
Кәбестә бит катлы-катлы,
Шунда ярала адәм.

— Мине кайдан алганнар? — дип,
Сораган кечкенәсе.
Әбинең җавабы әзер:
Судан тапканнар, янәсе.

Пыш-пыш иткән ике оник:
— Дөресен әйтик микән?
Әйтсәк, аңлар хәле бармы,
Әбигә күптән сиксән?!

Озак уйлап сөйләшкәчтен,
Чыгарганнар, ди, карар:
Без белгәнне әбиебез
Белми торса да ярар.

## Җәлләмим

Икегез бер язмыш, дип,
Кемнәр уйлап чыгарган?
Кайвакытта шундый авыр
Мондый кырыс карардан.

Әллә инде мин түземсез,
Кайчак синдә чыдам юк.
Ары-бире тәгәрәтә,
Дөнья-карчык шундый шук,

Тик шулай да мин рәхмәтле
Безне кушкан Аллага.
Садакамны һич җәлләмим
Никахлаган муллага.

## Әйт әле

Әйдәле, күбәләк,
Сөйләшик бергәләп —
Дөресен әйткәнгә
Очма син үпкәләп.

Очасың, кунасың
Гөлләрдән гөлләргә;
Сафлыгың, яшьлегең
Калдырды кемнәргә?

Очма син аптырап,
Ышанып мутларга;
Көйдермә ялгышып,
Канатың утларда.

Бик кыска шатлыклар,
Бер көяз җәй генә.

Бер мизгел гомернең
Кадерен бел менә.

## Вакыт юк

Һәркем белә: шатлыклардан
Авыр чаклар күбрәк.
Кайгы-хәсрәткә бирешми,
Тибә дә тибә йөрәк.

Бик күпләр йөри юл эзләп,
Үтә алмый тауларны.
Мин, туры җан, юл эзләмим,
Ярып үтәм ташларны.

Күпме ваттым, күпме баттым,
Утырып уйлар вакыт юк.
Тиз арада атылмастыр
Мине егар тимер ук.

## Тавык вәгъдәсе

Газетада хәбәр чыккан
Ай-һай иткән бар кеше.
Өч килолы йомыркага
Ничек җиткән ди көче?

Тавык кырына җыелып
Килеп җиткән түрәләр,
Аны сөйләштерер өчен,
Җайлап тары сибәләр.

— Ничек итеп өч килолы
Зур йомырка салдыгыз?
Аннан да зурны салырга
Юкмы сезнең планыгыз?

Тавык ханым, кет-кет итеп,
Як-ягын караштырган.
Җайлап кына килештереп,
Тарылар кабыштырган.

— Үпкәләмәгез, җәмәгать,
Сөйләшергә вакыт тар,
Биш килолысын салырга
Минем әле уем бар.

## Картлык

Картлык бит ул сорап килми,
Калмый юлда тукталып.
Картлык та килеп җитте дип,
Зиһен кала чуалып.

Җилкәнә йомшак шәл салып,
Олылап каршыла картлыкны.
Картлыкны олылый белсәң,
Ул да булыр шатлыклы.

## Гомер

Эх, дусларым, гомер үтә
Яхшы юрга ат булып.
Аты начаррак булса,
Торыр иде тартылып.

Атларымны тотып торган
Дилбегә еллар микән?
Гомернең әйбәт чагында
Төшеп кала алсаң икән.

Кем каккандыр ул аткайның
Тоягына җиз дага?
Ялгышып туктап куйса ул,
Ташка сугып ут чыга.

Тартмыйм юргам дилбегәсен,
Чапсын, күңеле туйсын.
Тик бер теләк: минем янда
Бер чана дуслар булсын.

Дошманга да урын табам,
Минем күңел түрем кин.
Шулай тигез юырта бир,
Арма, юрга атым син!

## Исәнмесез, саумысыз!

Шаяртасым килеп китте
Беркөн күршегә кереп.
Сәлам бирдем мин аларга,
Авыз җәеп һәм көлеп.

— Хәерле иртә, күршеләр,
Исәнмесез, саумысыз!
Әтәчегез бозаулаган,
Нигә чыгып алмыйсыз?

Күрше, исемне җибәреп,
Ялганны чынга алды.
Ике кашын җыерып,
Кинәт кайгыга калды.

— Менә бәла, ул әтәчнең,
Нишлик, гадәте начар.
Бозау өстенә бозау,
Бозау бездә бер амбар.

Күршем әйтте яхшырып:
— Булсын сиңа ул бозау.
Бер-ике кыш кышлат та
Рәхәтләнеп сау да сау.

Ышанып киттем күршегә.
Менә сиңа пәрәмәч!
Сыерың күкәй саламы,
Әтәчең бозаулагач?!

## Уй

Бер тәмәке көйрәткәндә
Сорау бирәм күршегә:
— Авыр түгелме күрше, — дим, —
Илле ел яшәү бергә?

Күнелендә бервакыт та
Уйнамадымы шайтан түй?
Аерылып китим диген
Кермәдеме сиңа уй?

— Андый уйлар бервакыт та
Кермәде, — ди, — күңелгә.
Тик шулай да ничә тапкыр
Уй булды бәреп үтерергә.

## Юксыну

Юллар буйлап, моңга калып
Йөри минем күңелем.
Җилләр пышылдап әйтер күк
Кинәт аның исемен.

Күкләргә очып, кошчык булып
Кагынасың, йөрәгем.
Күрмәгәнне, белмәгәнне
Ник сагынасың, җүләрем?

Томан баса су буйларын
Көзге моңсу таңнарда.
Хыялларым, өметләрем
Чыклар булыр, тамар да.

## Көзге

Көзгегә карап торам да,
Алдыйсың мине, диям.
Мин бит әле картаймаган,
Кыска итәкләр киям.

Көзгегә карап алам да
Йөгереп базарга барам.
Чәчем агарганын күреп,
Мин аңа буяу салам.

Көзгегә карама, диеп,
Көнелем бирә киңәш.
Көзге биргән яшькә түгел,
Күңелең белән тиңләш.

Ә хәзергә йөгереп йөри,
Яшең күңлеңнән сора.
Чын яшеңне белмәс өчен,
Көзгегә әзрәк кара.

## Оныт мине

Оныт мине, авыр чакта
Тик төшим мин исеңә.
Оныт мине, ерак юлда
Күреним мин күзеңә.

Оныт мине, уйлама да,
Тик күр мине төшеңдә.
Ерактагы йолдыз булып
Янып йөрим күңлеңдә.

Язмышыңда янгыр явып,
Басып китсә жаныңны,
Кил, диеп, син мине чакыр,
Онытып оныткаңныңны.

## Әй мәхәббәт

Әй мәхәббәт, мәхәббәт,
Мәхәббәт — син исерек.
Чайкаласың, тибрәләсең
Судагы көймә кебек.

Әллә эчтең инде тагын
Язларны ширбәт итеп.
Һаваларга карый-карый,
Киткән кошларны көтеп.

Кинәттән җырлый башлыйсың,
Таллардагы кош булып.
Уйламаганда елыйсың,
Күзләреңә яшь тулып.

Язлар булып, көзләр булып,
Кыш буласың җәйләрдә.
Көймә булып, юл югалтып
Йөзәсең җанда, тәндә.

Исертәсең аек баштан,
Югалтып зиһеннәрне.
Малай хәленә төшереп
Акыллы адәмнәрне.

Әй мәхәббәт, мәхәббәт,
Нигә болай шаян син?
Бәхет һәм зур хәсрәт булып
Бу дөньяга туган син.

## Таягыма

Озын юлдан ялгыз барам,
Аягым, җаным талды.
Янымда бер юлдаш булып
Тик тал таягым калды.

Күзге юлда бигрәк авыр,
Егылам диеп куркам.
Таяксыз калсам нишлим соң,
Төшермим аны кулдан.

Юлга чыкканда, янымда
Дусларым бик күп иде.
Кайсы калды, кайсы талды,
Кайсы алдалап китте.

Ялгызым мин, күзге юлда
Тая-шуа аягым.
Миңа егылам дигән чакта,
Тотып кала таягым.

Таягым син, тал таягым,
Минем сүзсез юлдашым.
Сине шулай тиң итәмен,
Ялгыз булганга башым.

## Бәхет

Мин бәхетсез, дигән кеше
Дөньялыкта өметсез,
Ул яналмас йолдыз булып,
Аның күнеле ямьсез.

Яшәгәндә бар да була,
Тик өзелмәсен өмет.
Өметләнеп яшәү белү —
Дөньялыкта зур бәхет.

Өзелмәсен өметен,
Өметсез — шайтан, диләр,
Уттай янган кеше генә
Бәхетле була белер.

Оял син бәхетем юк, дип,
Авыз ачып сөйләргә.
Көл, җырла, тик шул вакытта
Бәхет керә өйләргә.

* * *

Нишләргә соң, нишләргә?
Күз яшьләремне биримме
Синең назлы беләгеңә
Беләзеккә тезәргә?

Минем ачы яшьләремне
Санарсың да карарсың.
Кайдан алдың энҗеләр, дип,
Исең китеп сорарсың.

Ничек җавап бирим икән,
Минем яшьләрем, диеп.
Шушы ачы яшьләремнән
Калса да күзем көеп.

* * *

Мине дошман куралмый,
Талдан читән уралмый.
Үреп карый, сүтеп карый,
Тик берни булдыра алмый.

Менә төртеп егам дисә,
Борылып карыйм аңа.
Мин елыйсы ачы яшьләр
Аның күзеннән тама.

Әйтмим аны начар диеп,
Мин дә фәрештә түгел.
Тик аның ямьсез уйларын
Сизә бит минем күңел.

Сүтеп атам читәннәрен,
Янасын ясамаслар.
Мин бит табан балык түгел,
Пешереп ашамаслар.

* * *

Җаным, җаным, җаным, диеп,
Җаныма керәсең дә.
Син минем җаным түгел лә,
Үзең дә беләсең лә.

Ни белән бетәр бу хәлләр,
Рәнҗеп утырып еларсың.
Түземлегең җитеп калса,
Бәлки, җаным буларсың.

Кайда гына карасам да,
Синең күзеңне күрәм.
Кайсы җиремне яраттың,
Саташтың минем белән?

* * *

Су буенда ялгыз гына
Атым эчерткән идем.
Син төшәрсең яныма дип,
Зарыгып көткән идем.

Атым туйды, башын борды,
Мин киталмый таптанам.
Куак артында көләсең,
Мин беләм бит, син шаян.

Көләсеңдер, торсын диеп
Чибәр егет сызгырып.
Әллә инде юкка йөрим
Яшьлегемне уздырып.

Гармун уйнап, урамында
Кичләр буе уйланам.
Йокы бирмисең, дия дә
Чыгып бәйләнә атаң.

Бер батырлык кылам әле,
Бар авылны ич итеп.
Сине беркөн урлап качам,
Карт атаңа үч итеп.

## Шигырьләрем

Шигырьләрем — минем улларым,
Алар чыга җанымнан.
Нинди чакларым булса да,
Китмәс алар янымнан.

Шигырьләрем — минем кызларым,
Таңнар атканда туган.
Яңа шигырем туган саен,
Үзем тугандай булам.

Шигырьләрем — минем бәхетем,
Еллардан көтеп алган.
Шигырьләремне укысалар,
Мин бәхетсез булалмам.

Шигырьләрем — минем җырларым,
Күкләргә күтәрелгән.
Күтәрелүләр авырга
Аларның кадрен беләм.

Шигырьләрем — минем дусларым,
Охшаганнар ак карга.
Кара уйлар мине басмас,
Эчкерсез дуслар барда.

## Мин

Мин, мин, диеп, сүз сөйләмә,
Мин, дигән, ул — шайтан.
Мин дигән сүздән качар
Акылы булган адәм.

Мин, мин, диеп, сүз сөйләмә,
Булма син гөнаһлы.
Мин, мин, дигән кешенең
Зәгыйфь булыр акылы.

Мин, диеп, шайтан төртер,
Әйтәсең килмәсә дә.
Шайтансыз яшәргә өйрән,
Менә сиңа мәсьәлә!

## ЭЧТӘЛЕК


Без исән! *Рафис Корбан* . . . 3

**Мәүлекәй Юмачиков** . . . 9

Эрбет бәете . . . 10

«Эрбет бәете» турында. *Заһир Ислам* . . . 32

**Булат Сөләйманов** . . . 36

«Мин төп Себер татарымын чыгышым белән...» . . . 37

Самотлор . . . 37

Түбән Варта . . . 38

Самотлорда җәй уртасы . . . 39

Ак төн . . . 40

Самотлорда туй . . . 40

Манси жыры . . . 42

Төньяк, тундра . . . 43

Сопра . . . 44

Тобол . . . 46

Көзге урманда . . . 47

Китүләре бигрәк авыр икән . . . 48

«Кыр казлары үтте...» . . . 49

Мин бер серле . . . 49

Казанга . . . 50

Толымбай . . . 51

Иделдә . . . 53

«Уйный җилләр нинди кылларда...» . . . 54

Әйтмәгез Себерем хакында . . . 55

«Күптәнме җәй иде...» . . . 56

«Мин ялгызым йөрим урамда...» . . . 57

«Күренәме Себер Казаннан?..» . . . 58

Тукай кабере янында . . . 59

Кичен. Аккош күле . . . 60

Мин кайтырмын . . . 61

Казаннан китәр алдыннан . . . 61

**Шәүкәт Гаделша** . . . 63

Сазлык . . . 64

«Ботаксыз наратны...» . . . 65

«Авылдашларым жылым тарта...» . . . 66

«Улы карт анасына хат язды...» . . . 66

Тундра кызы жыры . . . 67

«Сердәшләр булганга...» . . . 68

Балык шулпасы . . . 69

Аучы жыры . . . 70

Танын ауда азан ишеттем . . . 75

«Язмышымның дәрьясы...» . . . 76

«Урман шәрә, жил тундыра...» . . . 77

Пошы аткач . . . 78

Яңа уй . . . 79

Черкине сагынам . . . 84

Себер татары . . . 85

Нинди Төмән? . . . 86

Мин бүген хан . . . 87
Чалдон теле . . . 89
Күңел елый . . . 90
Гаҗәп авыл . . . 91
**Николай Шәмсетдинов** . . . 93
Себер . . . 94
Обь . . . 95
Юл чәе . . . 96
Болан . . . 98
Кичке паром . . . 99
**Заһид Акбүләков** . . . 101
Омтыламын . . . 102
Әниләрнең яшь чагы . . . 102
Кошкайларым . . . 103
Тап төшермик . . . 104
Нәсыйхәт . . . 105
**Гөлнур Хәйруллина** . . . 106
Туган телем . . . 107
Авыз пешкәч . . . 107
Себерем — алтын бишек . . . 108
Хәерле иртә . . . 109
Берсе минеке . . . 109
Чәчләр чәчкә бәйләнгән . . . 110
Ник булмадым . . . 111
**Галия Абайдуллина** . . . 112
Саргаймагыз газиз аналарны! . . . 113
Яратам мәктәбемне . . . 114
Мәхәббәтнең яше булмый икән . . . 115
Җәлил шигырьләре . . . 116
Озак яшә, «Яңарыш»! . . . 117
Туган тел турында мөнәҗәтләр . . . 119
Тел . . . 120
Кемгә кирәк бу сугыш? . . . 122
Халкыбызның күркәм йолалары . . . 123
Хуш килдең, Яңа ел! . . . 124
Хуш киләсең, нурлы яз . . . 125
Күчем хан . . . 126
Саклап калыйк туган телебезне . . . 127
Татарым . . . 128
Хәерле иртә . . . 129
Дусларым . . . 130
Әнием — кояшым . . . 131
«Яңарыш»ны яратам . . . 132
Сәләм кисәге . . . 133
Себерем . . . 134
**Сәгыйть Сәгыйтов** . . . 135
Авылымны сагынам . . . 136
Авылга кайту . . . 136
Онытмагыз әниләрне... . . . 137

Мин яратам . . . 137
**Фәхрижамал Үтәшева** . . . 138
Җәйге иртә . . . 139
Авыл өе . . . 140
Кайда сез? . . . 140
Синен сөю . . . 141
**Клара Кучковская** . . . 142
Шигырьләрем — бүләгем . . . 143
Яратам мин . . . 143
Белми торсын . . . 144
Жәлләмим . . . 144
Әйт әле . . . 145
Вакыт юк . . . 145
Тавык вәгъдәсе . . . 146
Картлык . . . 146
Гомер . . . 147
Исәнмесез, саумысыз! . . . 148
Уй . . . 149
Юксыну . . . 149
Күзге . . . 150
Оныт мине . . . 150
Әй мәхәббәт . . . 151
Таягыма . . . 152
Бәхет . . . 153
«Нишләргә сон, нишләргә?..» . . . 153
«Мине дошман куралмый...» . . . 154
«Жаным, жаным, жаным, диеп...» . . . 154
«Су буенда ялгыз гына...» . . . 155
Шигырьләрем . . . 156
Мин . . . 157

Литературно-художественное издание

**Я — сибирский татарин!**

*Стихи*
Составитель **Р.Х.Курбанов**
Казань. Татарское книжное издательство. 2006
*На татарском языке*

Әдәби-нәфис басма

**Мин — Себер татарымын!**

*Шигырьләр*
Төзүчесе ***Р.Х.Корбанов***

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*. Рәссамы *А.П.Петрова*. Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*. Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Т.В.Гредюшко*. Корректоры *Г.М.Хәбибуллина*. Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.03.2006. Форматы 70×108 1/32. Офсет кәгазе. «Korina» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 7,0. Шартлы буяу-оттиск 7,35. Нәшер-хисап табагы 6,06. Тиражы 1000 д. Заказ 3-138. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. http://www.tatarstan.ru/books/ E-mail: tki@books.kazan.ru. Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААЖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.